БЕРДӘМЛЕКТӘ – КӨЧ

Авыл халкы күмәк эшкә кеше табып булмаудан зарлана

> 5

ДАЯН МУРЗИН

Гитлер «кара генерал»ны тотучыларга күп акча вәгъдә итә

> 16

ҖЫР БӘЯСЕ

Зөфәр Хәйретдинов – татар эстрадасындагы шау-шу турында

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 180 (28762) | Җомга | 10 декабрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

АЧУЛАНМЫЙ ТОРГАН МӘКТӘП

ӨЙДӘ УКУЧЫ БАЛАЛАР САНЫ ЕЛДАН-ЕЛ АРТА

Узган ел илдә 10 мең бала өйдә укыса, быел бу сан 13 меңгә җиткән. Сүз гадәти мәктәпләрдә белем алучыларның «гаиләдә укыту» төрен сайлавы турында бара. Бу укучыларның мәктәптән туюына бәйлеме, әллә алар ирек ярата башладымы? «ВТ» хәбәрчесе өйдә укытуның уңай һәм тискәре якларын белеште.

> 15

Ишетми калмагыз

РКБ – иң шәп хастаханә

Татарстанның Республика клиник хастаханәсе «Медицина һәм сыйфат – 2021» халыкара конференциясендә Россиядә иң яхшы клиника буларак танылган һәм «Медицина эшчәнлегенең сыйфаты һәм иминлеге өчен» премиясенә лаек булган. «Пандемия шартларында яхшыруыбыз, камилләшүебез аерым бер мәгънәгә ия. Бүген коронавируска каршы көрәшнең алгы сафларында армый-талмый эшләүче хезмәткәрләребезнең тырышлыгы нәтиҗәсе бу. Фидакарьләрчә эшләүче, көннән-көн камилләшә баручы коллективыбызга бик рәхмәтлемен», – ди баш табиб Рафаэль Шәвәлиев.

Эшмәкәрләр күбәйгән

Соңгы алты ай эчендә Татарстанда эшмәкәрләр саны 3 процентка арткан. Бу хакта Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитеты рәисе Лотфулла Шәфигуллин белдергән. «Пандемиягә карамастан, узган ел республикада кече һәм урта бизнес өлкәсендә эшләүчеләрнең санын саклап калуга ирешелде. Ярты ел йомгаклары буенча уңай динамика күзәтелә. Эшмәкәрләр саны ел башындагы күрсәткечкә караганда 3 проценттан күбрәккә артты», – дигән ул. Шәфигуллин билгеләп үткәнчә, республика икътисадының дүрттән бер өлешеннән күбрәген кече һәм урта бизнес (753,5 меңнән артыграк кеше) тәшкил итә. Гомумән алганда, Татарстан икътисадына барлыгы 1 миллион 952 мең кеше җәлеп ителгән.

Арадашчыларны тотканнар

Эчке эшләр министрлыгының Икътисади иминлек һәм коррупциягә каршы көрәш идарәсе хезмәткәрләре ноябрь аенда өч кешенең, коронавирустан вакцинация узу турында 3 кешегә ялган белешмә юнәтү өчен, 37,5 мең сум күләмдә ришвәт тапшыруда арадашчыга әйләнүен билгеләгән. Алар акчаның бер өлешен үзләрендә калдырган, калганын тагын бераү аша шәһәр хастаханәсендә эшләүче шәфкать туташына биргән. Медицина хезмәткәре, прививка ясаткан дигән мәгълүматларны дәүләт хезмәтләре исемлегенә кертә белмәгәнлектән, хезмәттәшенә мөрәҗәгать иткән. Моны 10 мең сум бәрабәренә исемлеккә ялган мәгълүматлар керткән һәм тегеөч кеше вакцинация турында ялган сертификат алган.

Хәзер «Ришвәт бирүдә арадашчы» статьясы нигезендә җинаять эше кузгатылган. Аның буенча иң зур җәза чарасы – 5 елдан 10 елга кадәр иректән мәхрүм итү. Эшне тикшерү дәвам итә.

Районнарда ни хәлләр?

Актаныш

Районда инде 20 ел дәвамында «Игелек марафоны» уздырылып килә. Изге күңелле, мәрхәмәтле кешеләр сәламәтлекләре чикләнгән кешеләргә ихластан ярдәм кулы суза. Оешма-предприятиеләр, авыл хуҗалыгы берләшмәләре, эшмәкәрләр, шәхси затлар – бу хәйрия чарасыннан беркем дә читтә калмый. «Игелек марафоны»нда җыелган акча инвалидлар оешмасы каршында төзелгән комиссия тарафыннан гариза нигезендә мохтаҗларга бүленә.
(Актаныш-информ)

Азнакай

Районның картлар һәм инвалидлар йортында спорт мәйданчыгы ачылды. Коллектив «Сәламәт тормыш һәм туризм» проекты белән «Татнефть» җәмгыяте уздырган бәйгедә катнашып, 500 мең сумлык грант откан. «Узебездән дә 120 мең сум өлеш кертеп, заманча тренажерларга ия булдык. Хәзер интернат-йортта тәрбияләнүчеләргә сәламәтлекләрен ныгытыр өчен яңа мөмкинлекләр ачылды», – ди проектның башкарма җитәкчесе, социаль эш буенча белгеч Анастасия Кравченко. Әлеге тантаналы чарада район башлыгы Марсель Шәйдуллин «Татнефть» җәмгыятенә һәм бердәм, тырыш коллективка рәхмәтен җиткерде. «Интернат-йортта ремонт-төзекләндерү эшләренә быел гына да республика тарафыннан 3 млн сум акча бирелде», – диде Марсель Шәйдуллин.
(Азнакай-информ)

Мамадыш

«Сәламәтлекне саклау» илкүләм проектының «Беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү системасын үстерү» федераль программасы кысасында Кече Кирмән авылында модульле фельдшер-акушерлык пункты төзелде. Моның өчен Кече Кирмән һәм якындагы Норма авылы халкы өчен уңайлы урын сайланган. Бинага электр, су, канализация кертелгән. Барлык җиһазлар да кайтартылган, лицензия алынган – яңа объект үз ишекләрен ачарга әзер. Әлегә авыл фельдшеры Миләүшә Шаһиева халыкны Кече Кирмән мәдәният йорты бинасында кабул итә. «Барлык уңайлыклары булган мондый модульле пунктлар безнең районның күп кенә авылларында ачылды. Мин кайчан да булса безгә дә чират җитәр дип өметләндем. Тиздән без авыл халкына югары дәрәҗәдә медицина ярдәме күрсәтә алачакбыз», – ди ул.
(«Нократ»)

Арча

Район фельдшеры Азалия Борһанова «Земский фельдшер» программасы буенча 500 мең сум акча алган. Агымдагы елның августыннан бирле эшләүче яшь белгеч Яшел Үзән медицина көллиятен тәмамлаган һәм үз һөнәри эшчәнлеген авыл җирендә башларга ниятләгән. Шуннан соң бер тапкыр бирелә торган дәүләт ярдәме алган. Бу программа «Сәламәтлекне саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проектының бер өлеше булып тора.
(minzdrav.tatarstan.ru)

ГЕРОЙЛАР ИСТӘЛЕГЕ БУЫННАРНЫ БЕРЛӘШТЕРӘ

tatarstan.ru

Республикада Ватан Геройлары көненә багышланган бәйрәм чаралары узды. Казанның Җиңү паркындагы Мәңгелек ут янына чәчәкләр салу булды. Ратушада Геройларны хөрмәтләү йөзеннән тантаналы чара уздырдылар. Советлар Союзы, Россия, Социалистик Хезмәт Геройларын, Дан орденының тулы кавалерларын, шулай ук аларның якыннары һәм туганнарын Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

Ватан Геройлары көнен бәйрәм итү Җиңү паркында Мәңгелек ут янына чәчәкләр китерүдән башланды. Фәрит Мөхәммәтшин республика җитәкчелеге исеменнән чәчәкләр салды, ветераннар, Геройлар һәм аларның туганнары белән аралашты.

– Һәлак булган һәм үлгән 235 Герой исеме республикабыз тарихында алтын хәрефләр белән уеп язылган, – дип билгеләп үтте парламент башлыгы. – Безнең бурыч – аларның исемнәрен саклау, хөрмәтләү, батырлыклары турында истәлекне буыннан-буынга тапшыру, бүген исән-имин яшәүче Геройларны һәм аларның гаиләләрен кайгырту.

Дәүләт Советы Рәисе республика җитәкчелеге исеменнән тантанада катнашучыларны сәламләп, Татарстанда яшәүчеләрнең хаклы рәвештә үз Геройлары белән горурлануларын билгеләп үтте.

– Хәзерге вакытта Татарстанда 20 Герой яши, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Аларны хөрмәтләгәндә, арабыздан киткәннәрне сагыш белән искә алабыз. Сугыш кырында, окопларда һәлак булганнар алдында түбәнчелек белән баш иябез. Геройларның истәлеге төрле буыннар һәм төрле милләтләрне берләштерә, ә инде бөек Ватаныбызга лаеклы булу омтылышы яңа каһарманнар тудыра.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, республикада киләсе елда да Герой якташларыбыз истәлеген мәңгеләштерү буенча чаралар дәвам иттереләчәк. Советлар Союзы Герое Михаил Девятаевка, Россия Герое Игорь Груднов, фронтовик шагыйрь Фатыйх Кәримгә – һәйкәл, шулай ук Советлар Союзы Геройлары Петр Гавриловка, Мәгубә Сыртланова, Борис Кузнецов, Россия Герое Рәфәгать Хәбибуллинга бюст куелачак.

Тантаналы чара азагында Фәрит Мөхәммәтшин Россия Герое Газинур Хәйруллин һәм Социалистик Хезмәт Герое Николай Фроловка – «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медальләрен, Социалистик Хезмәт Герое Радик Җәләевкә «Фидакарь хезмәт өчен» Татарстан Республикасы медален тапшырды.

Теманың дәвамы 16 нчы биттә >

Премьер-министр Алексей Песошин Казан Кремлендә Россия һәм Татарстанның дәүләт бүләкләрен тапшырды. «Татарстанда яшәүчеләрнең җитеш тормышы – безнең уртак хезмәтебез нәтиҗәсе. Сезгә көндәлек хезмәтегез һәм республика уңышына керткән өлешегез өчен рәхмәт белдерәм», – диде Хөкүмәт җитәкчесе. Дәүләт бүләкләре белән 51 кеше бүләкләнде. Араларында нефтьчеләр, сәнәгать, энергетика, транспорт, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре, мәгариф, медицина тармагы вәкилләре, сәнгать әһелләре, физик культура һәм спортны үстерүгә өлеш керткән кешеләр бар. Коллегабыз Илдар Кыямов «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» исеменә лаек булды.

Бурычлар билгеле

Татарстанда халыкка иң якын 6 министрлык – Сәламәтлек саклау, Мәдәният, Мәгариф һәм фән, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, Спорт, Яшьләр эшләре министрлыкларының төп максатлары, бурычларын билгеләү буенча «Дәүләт хезмәтләре» порталында бер ай дәвам иткән тавыш бирү тәмамланды. Барлыгы 38 мең чамасы кеше тавыш бирган һәм 5 меңнән артыграк өстәмә фикер-тәкъдим калдырылган.

Мәгариф һәм фән министрлыгының максатлары, бурычлары өчен тавыш бирүчеләр саны барыннан да күбрәк – 10886 кеше. Халык сыйныфта тәрбия эшчәнлегенең психологик юнәлешен көчәйтү, шулай ук балаларны җинаятьчел субкультуралар йогынтысыннан, психологик басымнан саклауга күбрәк игътибар бирү ягында.

Яшьләр эшләре министрлыгы буенча күпләр үсмерләрне социализацияләү, аларга психологик ярдәм системасын үстерү өчен тавыш биргән. Яшьләрне укудан буш вакытта эшкә урнаштыру тавыш бирү рейтингында беренче урынга чыккан.

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы буенча фәкыйрьлеккә каршы көрәшү һәм мәшгульлеккә ярдәм итү бурычлары иң күп тавыш җыйган. Ә инде Сәламәтлек саклау министрлыгы эшчәнлегендә яман шешләрне алданрак ачыклау, шулай ук йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан интегүче балаларны диспансер күзәтүенә алу эшен яхшырту бурычлары беренче урынга чыккан.

Хәзер иң күп тавыш җыйган максатлар һәм бурычлар, шулай ук республикада яшәүчеләрнең фикер-тәкъдимнәре ведомстволарның иҗтимагый советлары утырышларында каралачак. Алар декабрь аенда онлайн форматта үткәреләчәк.

ТЕРЕЛГӘЧ ТӘ ОНЫТЫЛМЫЙ

Диспансеризация мәсьәләсенә әлегә кадәр җитди карамаган кешеләр дә коронавируслы чорда моңа аерым игътибар бирер, мөгаен. Чирдән соң сәламәтлекне кайгырту тернәкләнү чылбырында мөһим урынны алып тора. COVID-19 инфекциясеннән соң тирәнтен диспансеризациянең әһәмияте турында белгечләр аңлатты.

Чәч коелу, төшенкелек, елыйсы килү. Әле бу – коронавирустан соң кала торган «күчтәнәч»ләрнең бер өлеше генә. Казанның 7 нче шәһәр сырхауханәсе баш табибы Ольга Богданова сүзләренчә, чирләп терелгән кешеләр күп очракта менә шуннан зарлана.

– 2020 ел азагында элегрәк күзәтелмәгән мөрәҗәгатьләр белән килүче сырхаулар очрый башлады. 30 проценты чәч коелудан зарланды. Төрле психик тайпылышлар, барыннан да бигрәк төшенкелек өстенлек итә, кеше үзен ялгыз дип саный, даими рәвештә елыйсы килә. Моннан тыш буыннар сызлавыннан да зарландылар, – дип сөйләде белгеч. Араларында иң куркынычы – йөрәк һәм кан тамырларына бәйле үзгәрешләр икән.

Баш табиб сүзләренчә, коронавирус белән авырып алган өлкән яшьтәге кешеләрнең инфаркт һәм инсультка дучар булуы да ихтимал. Аныңча, коронавирус кичергән күпләр менә шушы сәбәпләр аркасында үләргә дә мөмкин. Моны кисәтү өчен тирәнтен диспансеризация кирәк тә.

Диспансеризацияне кемнәр узарга тиеш соң? Бу – иң элек, коронавирус кичерүчеләр һәм төрле чирләре булган кешеләр. Баш табиб әйтүенчә, диспансеризация вакытында кайбер терапевтлар сырхауларны психиатрга да җибәрергә мөмкин. «Менталь сәламәтлек турында да онытмау мөһим», – ди Ольга Богданова.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Марина ПАТЯШИНА, Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы:

– Татарстанда коронавируска каршы күмәк иммунитет күрсәткече 72 процентка җитте. 80 процентка да күп калмады. Моның өчен тагын 300 меңләп татарстанлы вакцина ясатырга тиеш. 9 декабрьгә караган мәгълүмат буенча, Татарстанда 2165389 кеше прививка кадаткан, шуларның 1854987се вакцинаның икенче компонентын алган. Шулай да 60 яшьтән өлкәнрәкләр арасында вакцина ясату күрсәткече түбән. Коронавирустан үлүчеләрнең күп өлеше бу категориягә туры килә. Әлеге категориягә караган кешеләрнең бары тик 60 проценты гына вакцина ясаткан.

ӘТИ ДӘ ЮК, АКЧА ДА...

Татарстанда алимент түләмәүчеләрнең бурычы 2,5 млрд сумга җыелган. Республикада 38 мең кеше якыннарына матди ярдәм күрсәтми. Шуларның 85 проценты – ир-атлар. Бурычлы 2,5 мең кешенең, гомумән, кайдалыгын белмиләр.

pixabay.com

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе урынбасары Елена Варфоломеева сүзләренчә, быел республикада алимент бурычы булган кешеләрдән 450 миллион сум акча түләткәннәр. 2 мең кешенең милкенә арест салынган.

Ни өчен бурычлылар алимент түләүдән кача? Аларны ничек дөрес юлга кертергә? Бу хакта Татарстан Иҗтимагый палатасында узган очрашуда сөйләштеләр. Әлеге чараны «Татарстанның күпбалалы гаиләләре» оешмасы рәисе Артем Кузнецов тәкъдиме белән оештырганнар. «Соңгы арада алимент алмаучы әниләрнең зарын күп ишетәбез», – ди ул.

– Аеруча авыру бала үстерүче әниләргә кыен. Алар, баласы авыргач, эшли дә алмый, ә яшәргә кирәк. Суд приставларының да эше күп. Әмма алимент түләүне җайга салырга кирәк. Бездә җайлы – кеше рәсми рәвештә эшли икән, акчасы тотыла. Аның исемендә булган карталарга арест салына. Чит илгә чыгуны тыялар. Шуның белән шул. Ә бит кеше рәсми рәвештә теркәлмичә дә эшли ала. Акчаны карта аша гына түгел, кулга да бирәләр. Читкә дә чыкмыйча яшәп була, – ди Артем Кузнецов.

Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева фикеренчә дә, гаиләдә бала интегергә тиеш түгел.

– Ир белән хатын бала алып кайтырга уйлый икән, алар бу сабый алдында җаваплы икәнлекләрен дә белсен иде. Әни кешегә, үзе генә калгач, тормыш алып бару авыр. Кайберәүләр, акча түләмәс өчен, рәсми эшкә махсус урнашмый, урнашса да, акчасын киметеп күрсәтә. Кайберләренең өчәр баласы тилмереп яши, – ди Зилә Вәлиева.

Артем Кузнецов алимент түләмичә качып йөрүче әтиләргә карата кырысрак булырга кирәк, дигән фикердә.

– Әйтик, ул кешеләр машина йөртү таныклыгын алыштырырга килгәч, аны бирмәскә кирәк. Бәлки, шулай эшләү баласы барлыгын, аңа акча кирәклеген исенә төшерер. Кеше банкка кредит түли алмаса, бу эшне коллекторларга тапшыралар. Ә нигә алимент түләмәүчеләрне дә алардан эзләтмәскә? – ди ул.

Татарстанның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская да халыктан алимент түләмәү буенча зарларның күп килүен әйтте.

– Суд приставлары эшне вакытында башкарсын иде. Кеше бер районнан икенчесенә күченгәндә, ике көндә эшләнәсе эш айларга сузыла. Документлары югалып бетә. Менә шушы эшне дә җайлыйсы иде, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Айдар ШӘЙХИН

БЕЛЕМ – ГЫЙЛЕМ

Белем һәм *гыйлем* сүзләрен ничек итеп дөрес кулланырга? Аларның аермасы стилистик үзенчәлекләрдә исәпкә алганда яхшы күренә.

Беренчедән, *белем* – төрки сүз, аның борынгы формасы – билик/белек. «Котадгу белек» әсәренең исеме, мәсәлән, нәкъ шул чорга, төрки телебезнең борынгы дәверләренә кайтара һәм *белем* сүзенең никадәр тарихы барлыгын чагылдыра. Аның белән аваздаш сүз дә бар: *билге*. Борынгы төрки телдә ул зирәклекне, акыллы булуны аңлаткан.

Гыйлем сүзе дә бик мәгънәле һәм борынгы: ул телебезнең гарәп теле белән бәйләнешен, ислам дине белән бергә килгән яңа гыйльми мәдәниятнең тарихыбызда урынын күрсәтә. *Гыйлем*, беренчедән, *белем* сүзенең синонимы булып торса, икенче яктан, ул *фән* төшенчәсен дә аңлата ала.

Гадәти очракларда, *гыйлем* сүзе урынына *белем* сүзен куллану дөресрәк булып күренә. Чөнки стилистик төсмерләре белән гарәп сүзе барыбер искерәк булып яңгырый. Шул ук вакытта *гыйлем* – затлы сүз, аның ярдәмендә җөмләне матурларга, тирәнрәк мәгънә салырга мөмкин. Дини текстларда ул сүз беренче урында тора, чөнки ислам дине очрагында *гыйлем* ул гадәти сүз генә түгел.

Белемнәр яки *гыйлемнәр* дип сөйләшергә ярыймы? Менә монысы – проблемалы очрак. Мәгънәсе ягыннан карасак, белем берничек тә күплек санда була алмый: ул – абстракт төшенчә. Шуңа күрә мөмкин булганча *белем* яки *гыйлем* сүзләрен берлек санда гына кулланырга кирәк. Аның дәрәҗәсен *күп/аз* кебек сүзләр ярдәмендә күрсәтергә була.

Гыйлем гарәп сүзе булгач, аның гарәпчәдән кергән күплек формасы болай да бар: *голум* дигән сүз «гыйлемнәр» дигәнне аңлата да инде.

Әгәр дә *гыйлем* яки *белем* дип мәгълүмат күплегеннән бигрәк, конкрет бер юнәлештәге, системалы мәгълүмат җыелмасы, ягъни фән аталса (мәсәлән, *әдәбият белеме, сәнгать белеме, хәдис гыйлеме, сира гыйлеме* һ.б.), бу очракта күплек санга күчереп, *дини гыйлемнәр, гуманитар белемнәр* рәвешендә куллану дөрес була ала. Әмма, кирәксә-кирәкмәсә, кагыйдәләрдән чыгарма ясарга киңәш итмәс идем.

КАРШЫНДА – КАРАМАГЫНДА

«При Президенте, при Министерстве, при мечети...» кебек сүзләрне татар теленә тәрҗемә иткәндә *«каршындагы»* дигән бәйлек сүз кулланыла. Аның турында филологлар һәм журналистлар арасында бәхәсләр булды инде. Аңа алмашка башка сүзләр дә тәкъдим ителде, әмма лингвистик чынбарлык шундый: *каршындагы* сүзе татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә теркәлгән инде. Аңлатмалы сүзлектәге билгеләмәсенә игътибар итегез: «нинди дә булса оешмага һ.б. буйсынган (шуның идарәсендә) булу мәгънәсен белдерә һәм кушма аергыч ясап килә». Димәк, *Татарстан Президенты каршындагы комиссия* дигән тезмә дөрес була.

Хәер, *при* приставкасын татар телендә *карамагындагы* бәйлек сүзе дә алыштыра ала. Ул да идарә структурасында буйсынуны аңлата. Шул рәвешле, *Татарстан Президенты карамагындагы Эшмәкәрлек советы* дигән атама да, *Татарстан Президенты карамагындагы Дәүләт торак фонды* атамасы да дөрес дип табыла.

Каршындагы сүзе, билгеле, күпләргә ошамый. Ул урынсыз, ясалма, калька булып күренә, яңгырашы ук кәефне төшерә. Шуңа күрә матбугат чараларында аны *хозурында/хозурындагы* сүзенә алыштыра башладылар. Чыннан да, *хозурында* сүзе кемнең дә булса янында, каршында булуны аңлата (әмма *хозур* сүзе үзе башка мәгънәдә йөри). Шул ук Президент комиссиясенең дә атамасын *Президент хозурындагы* дип яза башладылар. Моның мәгънәсе бар, әлбәттә. Табигыйрак яңгырый сыман. Өстәвенә дини әдәбиятта бу сүз актив кулланыла һәм *Аллаһ хозурында* дигән сүзтезмәне бик еш очратырга була. Бу яктан *Президент хозурында* тезмәсе әле борынгырак, «шәрекъчәрәк» тә яңгырый. Шуңа күрә бу вариантны кулланырга ярый.

Әмма рәсми документларда *каршындагы* варианты кулланыла. Президент комиссиясе дә аны оештыру турында карарның татарча текстында *каршындагы* комиссия дип аталган.

Әйтеп кенә бактым

Вертикаль

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бу рубриканы инде ике елдан артык алып барам. Шөкер, «ВТ»ның җомга санындагы дүртенче битне ачып, Риман тагын нәрсә язды икән?» – дип кызыксынучылар күп икән. Шул ук вакытта рубриканың исемен бик үк ошатып бетермәүчеләр дә табылды. «Әйтеп кенә бактым» дип куйгач, мине бик куркак кеше дип күз алдына китерәләр икән. «Син туры сүзле бит!» – дип, күңелне дә күтәргән булалар.

Анысы шулаен шулай да, тик кайчак «барабан каксалар, барабан артыннан, кубыз тартсалар, кубыз артыннан» барырга да туры килә бит.

Күптән түгел атаклы хәйрияче Әсгать Галимҗанов турында китап чыгу уңаеннан мәкалә язган идем. Шул вакытта Әсгать абыйның дуңгызлар симертүе, шуларны саткан акчаны балалар йортларына бирүе һәм кардәшләребезнең: «Татар кешесе дуңгыз асрарга тиеш түгел, бу хәрам!» – дип, кара тавыш чыгаруы искә төште. Шуннан соң татарга дуңгыз асрау хәраммы-юкмы икәнен белешер өчен, дин әһеленә шалтыраттым. Әмма анык кына җавап ишетмәдем. Газетадан икәнемне дә әйткәч, ул миңа Диния нәзарәтенең матбугат белән эшләү бүлегенә шалтыратырга киңәш бирде. Мин әлеге хәзрәтне гаепләмим, исемен дә язмыйм. Шунысы гына гаҗәпләндерде: «хакимият вертикале» дигәннәре дингә дә үтеп керде микәнни? Халыкка Коръән сүзен җиткерү өчен кемнәндер рөхсәт алу кирәк микәнни? Хәзрәткә шулай дип әйтеп карыйм, әмма ул: «Юк, юк, Диния нәзарәтенә шалтыратыгыз, иншалла, җавап бирерләр», – дип, миннән тизрәк котылырга теләде. Әлбәттә, «өстәге»ләргә шалтыратмадым инде, ә бер танышым, шулай ук дин әһеле белән сөйләшеп алдым. Дөресен әйткәндә, ул да бераз сагайды. Дуңгыз асрауның мөселман кешегә гөнаһ икәнен әйтте үзе, әмма: «Болай да башка сугарга торалар», – дип, исемен язмаска кушты, аннан соң бер кызыклы вә гыйбрәтле фикер әйтеп куйды. Ягъни мәсәлән, бездә мәчет-чиркәүләр төзергә яки төзекләндерергә акча бирүче байлар бар. Әмма алар биргән акчаның барысы да хәләл көч белән табылганмы соң? Аның бу шигә белән килешәсе дә килә. Чөнки бездә хәләл көч белән күп-күп акчалар эшләү бик ансат түгел дип беләм. Сирәк булса да йә кеше өлешенә, йә дәүләт кесәсенә керергә туры килә, бөтен халыкныкы саналган табигый байлыкларны да үзеңнеке итәсе килә. Шул ук вакытта нәфесне тыю дигәннәре дә бар бит әле! Нәрсәнең – хәләл, нәрсәнең хәрам икәне турында бәхәсләшергә җае чыгып кына тора, каһәр.

Ярый әле җәмгыять законнары кешегә якын һәм хакимлеккә килгән һәркем аны үзенә «якын» итеп, теләсә ничек үзгәртә ала, хәтта Төп Закон – Конституциягә дә кул тыга. «Закон – дышло, куда повернул – туда и вышло» дигән күркәм әйтем дә барлыкка килде. Аны бик яратып кулланабыз һәм «Закон – тайга, медведь – хозяин» дигәнен дә өстәп, рәхәтләнеп яши бирәбез. Болары күңелне юату өчен генә әйтү инде, «хакимият вертикале»ндә һәрберебезнең дә урыны бар, «шык» та итә алмыйбыз. Һәм, иң кызыгы, мондый яшәешкә шулхәтле күнеккәнбез: безгә рәхәт. «Шеф» көлсә – көләбез, ул каш җыерса, без дә йөзгә җитди кыяфәт чыгарабыз. Җыеннарда сүз бирсәләр, мөнбәр артына басып, күз кырые белән әледән-әле президиум ягына карап, чыгыш ясыйбыз. Янәсе, сөйләгән сүзләребез җитәкчеләргә ошыймы? Әгәр йөзләрендә елмаю, канәгатьләнү чалымнары чагылып китсә, тагын да хисләнеп сөйләргә тотынабыз. Шөкер, безнең өчен уйлаучылар бар. Кайсы илдә бар мондый тормыш! Җитәкчелеккә акыллы кешеләр генә килсен инде, бөтен теләк шул. Чөнки соңгы бер гасыр эчендә хакимлеккә килүчеләр арасында бер генә җүнле кеше дә булмаган икән. «Тәхет»тән киткән берсен эттән алып эткә сала барганнар. Ленины, Сталины, Хрущевы, Брежневы... Берсе дә яхшы кеше булмаган, шуңа күрә илебез бик чәчәк ата алмый, имеш. Бераз алга йөгерәбез дә тагын артка китәбез, имеш. Ягъни бер урында күбрәк таптанабыз.

Диндә мондый нәрсә була алмый дип уйлыйм. Беренчедән, Конституция буенча, дин дәүләттән аерылган. Шәригатьнең үз законнары бар һәм аларга берәү дә кул тыга алмый. Шул заман шаукымына ияреп киткәләсә генә инде. Әмма хакимият вертикале диндә урнаша алмас ул. Чөнки Аллаһы Тәгалә каршында бөтен кеше дә бертигез.

Инде рубриканың исемен өнәп бетермәгән дустыма: «Менә әйтергә теләгәнне һәм әйтә алганны әйттем инде, башкасын өсти алмыйм», – диясе килә. Ул – акыллы кеше, артык сүз сөйләргә ярамаганны үзе дә белә. Әле дустым Алмаз Хәмзиннең әбисе Мәликә карчык, йөз яшенә җиткәч тә, оныгы Алмазга: «Улым, сүзеңне әйтер алдыннан тел очында әйләндереп кара, әчесе юкмы?» – дип әйтә торган булган. Менә вәйт!

ТАРКАТА ТОРГАН КИЛЕШҮ

Бу юллар бөек тарихи датаның утыз еллык юбилее тулган көндә – 8 декабрьдә язылы. Утыз ел элек нәкъ менә шушы көнне өч союздаш республиканың лидеры – Ельцин, Кравчук, Шушкевич – бернинди дә вәкаләтләре булмауга карамастан, легендар Брест крепостеннан 70 километр ераклыктагы Вискули дип аталган хөкүмәт дачасында СССРны дәүләт буларак юкка чыгара торган килешүне имзалады.

Әйе, СССР яшәп кала алмый иде инде, чөнки бер халыкның өстенлегенә корылган аркадашлык озак гомерле булмый. 1922 елгы Союз килешүе 70 елын да тутыра алмыйча, хурлыклы рәвештә өзелде. 1991 елда илдә анархия хөкем сөрә иде: акчаның бернинди кыйммәте дә юк, кибет киштәләре шыр буш (чират торып алырга да берни калмаган), илгә ачлык куркынычы яный... Соңгысы бик гаҗәп инде, чөнки иксез-чиксез кырлар тутырылып иген үстерелә, фермалар тулы мал-терлек, шуңа өстәп 22 миллион тонна ашлыкны читтән сатып алганнар, әмма декабрьдә кибет киштәләрендә диңгез кәбестәсеннән башка берни дә юк. Коммунизм үзенең яшәргә сәләтсез система икәнлеген Җир шарының алтыдан бер өлешен тәшкил иткән туфракта тулысынча һәм шикләнмәслек итеп раслады.

Балык башыннан чери башлый. Коммунизмны тормышка ашырырга тиешле җитәкчелек караклык, ришвәт, талаулар сазлыгына тулысынча төшеп баткан һәм фантастик идеянең утопия генә икәнлеген бар кеше дә ышанган иде. Гади коммунистлар партбилетларын пачкасы белән чүплеккә ташлаган елларның финалы бу. Хәлне төзәтмәкче булып, Горбачев ел башында СССРның югары җитәкчелеген тикшерергә әмер бирә. Тикшерүчеләр төркеме җәй ахырына кадәр тырышып эшләп, берничә йөз битлек куркыныч фактлар туплый. Аны укыган кешеләрнең чәче үрә торырлык булган дип әйтәләр. Алтын, кыйммәтле ташлар, күчемсез милек белән махинацияләр «досье»ның бик кечкенә өлеше генә була. Горбачев, укып чыкканнан соң, папка СССР Министрлар Кабинеты эшләре белән идарә итүче Простяков сейфына күчә һәм шуннан эзсез югала. СССРның берничә йөз тоннаны тәшкил иткән алтын запасын да шундый ук билгесез язмыш көтә. Һәм менә өч лидер декабрьнең кыска көнендә, башка аркадаш дәүләт җитәкчеләреннән һәм Горбачевтан качып, илнең көнбатыш чигеннән ерак түгел генә урында килешү имзалый һәм дөньяның иң куәтле державасының берсе булган дәүләткә матәм маршы уйнала.

Бу юлларның авторы ул көннәрне бик яхшы хәтерли. Тик бер нәрсәне ул чакта белми: фетнәче лидерлар үзләренең авантюрасы барып чыгасына үзләре дә ышанмыйлар. Кулга алырга килсәләр, чыгып качарга кулай булсын өчен, биш минутта чикнең теге ягында булырлык урында очрашалар.

Ул көннәрдә армиянең кем ягында булачагын иң югары җитәкчелек үзе дә белеп бетерми. Аяк киемен барысына да чабып барган көйгә алыштырырга туры килә. 10 декабрь көнне Горбачев, 11 декабрьдә Ельцин армиянең югары команда составы белән очрашалар. Хәрбиләрне үз ягына аудару бурычын Ельцин уңышлы башкара. Көнбатышның мәгълүмат чараларында армия өч фетнәче Президентка каршы тора дигән хәбәрләр таратыла, әмма алар дөреслеккә туры килми. Ельцин хәрбиләрнең хезмәт хакын 1992 елның 1 гыйнварыннан 1,9 тапкыр арттырырга вәгъдә бирә, ул акчаның бернигә дә ярарлык булмаячагын, үзләрнең ярык тагарак алдында калачакларын хәтта хәрбиләр дә аңламый әле. Башка союздаш республикалар лидерлары да «фетнә»гә каршы чыкмыйлар. Ул чакта инде республикаларның «бәйсезлек парады» тулы көченә бара, анда соңгы «аяк тавышы» булып Казахстанның бәйсезлек турындагы акты – Югары Советның «Казахстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында» карары 16 декабрьдә игълан ителә.

1 декабрьдә исә украиннар, референдум үткәреп, үз дәүләтләренең бәйсезлеген раслыйлар. Нәкъ утыз елдан соң АКШ һәм Россия Президентлары телекүпердә очрашып, Россиянең Украинага бәреп керүен булдырмау мәсьәләсен хәл итәргә тырышырлар дип ул чакта кемнәр уйлаган? Уйлаучылар булган, әлбәттә. Ул чакта ук инде Украинада яшәүчеләрнең бары тик 35,8 проценты гына Россия – Укаина мөнәсәбәтләре цивилизацияле характерда, ягъни кешечә булыр дип ышанган. Күрәбез, 2014 елда башланган конфликт буш урында барлыкка килмәгән, тарихи алшартлары булган. Әмма шулай да килешик: ике туганнаш халыкның этле-мәчеле яшәп, канлы сугыш бусагасына килеп җитүе – сюрреализм инде ул. Башка сыймаслык хәл.

СССРның таркалуы коммунизмның финал аккорды буларак котылгысыз хәл иде. Безнең җилкәләргә ул бик авыр йөк булып басты. Эшләгәнебез-тапканыбыз бәрәкәтсезгә әйләнде, безнең хезмәт хаклары өстендә гиперинфляция биеде, акчаларыбызны доллар курсы белән берничә тапкыр тукмадылар һәм юкка чыгардылар, элекке СССР туфрагында канлы фаҗигаләр уйналды һәм уйналуы дәвам итә. 1991 елның декабрендә совет халыклары капитализмга ишек ачарбыз да, дистәләгән сортлы казылык сатыла торган кибетләргә килеп керербез, рәхәт яши башларбыз дип хыяллана һәм ул хыялларына эчкерсез ышана иде. Утыз елдан соң глобаль капитализм үзенең турбулентлык зонасына килеп керер һәм зур мәтәлчек башланыр дип уйларлык та түгел иде. 7 декабрьдә Байден белән Путин сөйләшүе уңышсыз тәгәлләнсә, безне яңадан конвертацияләнми торган сумга, икътисади яктан бикләнүгә хөкем итәчәкләр иде. Кичәге телекүпер вакыйгаларның мондый үсешен туктатып торды әлегә. Туктатып торды, чөнки Америка – глобаль капитализмның төп терәге булган дәүләт – үзенең элекке йогынтысын югалтып бара. Без кайчандыр омтылган икътисади система кабергә кереп ятарга җыена һәм табут капкачын кадаклаучыны көтә. Бу – котылгысыз әйбер. Система айкалганда һәм чайкалганда дәүләт лидерлары тырма өстенә еш басалар. Һәм тырма сабы аларның гына түгел, халыкларның маңгаена шап итә. Яңадан кыенлыклар аша узарга туры килә. Бер тапкыр җимерелүне кичергән кешеләрнең берсе буларак әйтә алам: җимерекләр астыннан чыгу кыен, әмма мөмкин эш ул. Шуңа күрә балавыз сыгудан файда юк.

Моннан утыз элек Горбачев, КГБчыларны чакыртып, «Беловежская пуща» дип аталган урында тиңе булмаган фетнә чыгарып, дәүләт җимереп ятучы өч лидерның кулына богау салырга әмер биргән булса да, тарих барыбер шул үз эзеннән атлаган булыр иде. СССР дигән дәүләтнең яшәрлек җае калмаган иде инде. «Реанимация палатасы»на салып та аны коткарып калу мөмкин түгел иде. Үткәннәр өчен елау – файдасыз эш, сабак алу яхшырак нәтиҗә бирә гадәттә. Без – татарлар өчен ул елларда милләт буларак үсешкә зур мөмкинлекләр мәйданы ачылган иде. Ул потенциальны империя көчсез вакытта тулысынча файдаланып кала алмадык, ваемсызлык сәбәпле оттырдык. Тарих спирале яңадан бөтерелә һәм аның шул бөтерелешендә үткәндәге сабакларны искә алырга иде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ЭШЕ БАРДА КЕШЕ ЮК

Авылларда элек-электән зур эшләрне күмәкләшеп эшләү гадәте булган. Шөкер, күпчелек җирдә бу матур гадәт әле дә саклана. Авыл халкының бердәмлеге каз өмәләре, мал эшкәртү, өй юу, печән ташу, бура күтәрү, мәет җирләү кебек зур эшләрдә аеруча нык сынала. Тик соңгы елларда халыктан зур эшләр башкарырга ярдәмчеләр табып булмау турындагы фикерләрне дә ешрак ишетергә туры килә. Моның сәбәбе нидә?

Тирес түккән өчен – 100 сум

Авыллардагы бердәмлекнең кимүенә берничә ай элек якынын югалткан Гөлүсә Ибраһимова да инанган.

– Хәзер авылда кабер казырга да кеше табу авыр, – ди ул. – Әлдермештә, мәсәлән, кабер казу өчен 25 мең сум сорадылар. Мәетне шәһәрдән җирләргә кайтардылар. Авылдашларына, бәлки, мөнәсәбәт башкадыр.

Шушы авылда яшәүче Тәлгать Сабиров исә: «Безнең авылда андый хәл барлыгын белмим, – дип белдерде. – Мәет булса, барыбыз бергә җыелышып, соңгы юлга озатабыз. Авылдашлар арасында акча түләп кабер казыту юк. Сугымга килгәндә, күрше Сая авылында яшәүче егетләрне дәшәбез. Алар килеп, оста гына эшкәртеп китәләр. Башка эшләрне күмәкләшеп эшлибез».

Ни генә булса да, көчле, кулы эш белгән тырыш ирләр һәм хатын-кызлар берләшеп, хезмәтләрен кәсеп итә башлауны берничек тә инкарь итеп булмый. Ягъни соңгы елларда республикада билгеле бер хакка каз йолку, сарык йоны алу, өй юу, мал эшкәртү һәм башка шуның ише эшләрне эшли алырдай хатын-кызлар һәм ир-атлар төркемнәре оешты.

Кукмара районының Төркәш авылында яшәүче Рәис Басыйров күрше-тирә авыллардагыларга мал абзарын чистартышырга, утын ярышырга, кар көрәшергә, башка вак-төяк эшләрен эшләшергә ярдәм итә.

– Бик еш мөрәҗәгать итәләр дип әйтеп булмый. Айга берничә тапкыр барып кайтырга туры килә. Гадәттә, өлкән яшьтәгеләргә булышам. Ялгыз хатын-кызлар да күп чакыра. Ирләре булып та, яки өлгерә алмаган, яки саулыклары булмаган, яки читтә эшләү сәбәпле, гаиләсенә авыр хезмәттә булыша алмаган кешеләргә дә барам, – ди Рәис абый.


«ВТ» архивыннан

Ул җәен авыл көтүен көтсә, кышын тормыш итәренә акчаны авыл мәчетенең мичен ягып һәм менә шушылай ярдәм итешеп таба.

– Дүрт ел элек бер апага булышкан идем. Шуннан күреп, башкалар да дәшә башлады. Аларга да яхшы, үземә дә ипитозлыкка ярап куя. Мал абзарын чистарткан, кар көрәгән өчен күп сорамыйм мин. Гомумән, акчаны сорап алганым юк. Күпме бирә алалар, шуңа канәгать булам. Гадәттә, бер-ике сәгатьлек эшкә 100 сум бирәләр. Ярап куя инде, мин ул эшләрне тиз эшлим бит. Шуңа күрә биргән акчаны азсынмыйм, артыгын сорый белмим. Мәчет мичен яккан өчен көнгә 150 сум бирәләр. Анысын салкын көнне генә ягабыз. Җәен көтү көтеп, аена 70–75 мең сум эшли идем. Ул акчаны әллә ни озакка җиткереп булмый. Малларга азык алырга китте быел, – диде Рәис абый.

Аның бертуган энесе дә кешегә булышып йөри икән. Мондый эшләрне эшләү өчен беренче чиратта сәламәтлек кирәк, дип саный алар.

– Кешенең нинди эше бар, барысын да эшли, – ди Рәис Басыйров. – Канау казырга да, тирес чыгарырга да, ашлык ташышырга да, кар көрәргә дә бара. Авыр физик эшләр инде. Аларны эшләргә сәламәтлек кирәк.

Соңгы елларда авылларда көчле, эш рәте белүче ир-атлар кимеган дигән фикердә әңгәмәдәшем. Булганнары да кешегә эшләми: «Элек безнең авылда шундый берничә кеше бар иде. Хәзер энем белән мин генә калдык. Көчле, гайрәтле ирләр башка җирләргә вахта белән эшкә йөри яки Казанга китте. Булганнары да халыкка булышырга килми. Авылда башка эше дә юк».

«Бер генә буш көнебез дә юк»

Ленар Йосыфҗановның төп кәсебе – сугымчылык. Ун ел инде ул халыкка мал эшкәртешергә ярдәм итә. Бригадада аның белән бергә йөри торган Наил Шәфигуллин 17 ел шушы эш белән шөгыльләнә булып чыкты.

– Февраль уртасына кадәр бер генә буш көнебез дә юк. Сугымчылыкта сезон дигән әйбер юк инде ул. Ел дәвамында эшлибез. Көн саен дүрт баш малны эшкәртеп өлгертәбез. Караңгы тиз төшә, аңа кадәр эшне төгәлләргә тырышабыз. Беренче сугымны иртәнге 6га билгелибез. Якын-тирәдә генә йөрсәк, күбрәк тә мал эшкәртергә булыр иде. Юлга вакыт күп киткәч, кышын дүрттән дә арттырып булмый, – ди Ленар Йосыфҗанов.

Сугымчылар Кукмара районының Купка авылында яшәсәләр дә, күрше-тирә районнардагы барлык авылларда йөри. Саба, Питрәчкә, хәтта Киров өлкәсенә дә чыгалар.

– Халык күп мөрәҗәгать итә. Моңа кадәр бер генә көн дә буш булганыбыз юк. Быел сугымга йөрү тагын да ешайды. Әлегә кеше малны күп асрады. Менә моннан соң ничек булыр – билгесез. Ризык кыйммәт булгач, бетерәбез, киметәбез, дип әйтүчеләр бар, – ди сугымчы абыйлар.

Сугымчылар сүзләренә караганда, еллар узган саен, аларның хезмәтенә ихтыяҗ артып кына бара. Чөнки маллар эреләнә, хуҗалары якын килергә курка.

– Малның холкын белеп булмый. Бик холыксызлары бар. Атлар янына бөтенләй керүче юк. Аларны асрау авыр. Без күбрәк менә шундыйларга йөрибез. Сугымга еш йөргәч, авылның хәлен чамалап була. Кайбер җирдә янда басып торырдай да бер ир-ат булмый. Кайсылары булса да, якын килергә курка. Шулай да, авылларда ярдәмләшү бетте дип әйтәсе килми. Без үзебез казлар асрыйбыз. Аларны туган-тумача, күрше-тирә өмә ясап эшкәртәбез, – диләр.

Бәяләргә килгәндә, үгез, танага – 2500, ат өчен 3000 сум алалар. Ерак ара булса, бензинга да бирүче бар икән.

– Күпчелек кеше ашап-эчеп чыгарга да дәшә, тик сирәк керәбез. Төшке аш вакыты туры килсә яки бик өшеп китсәк, кереп чәй эчеп чыгабыз, – диде Ленар Йосыфҗанов.

12 көнгә – 1029 баш сарык

Буа районының Чуаш Аксуында яшәүче Зинаида Журавлева үзенең тырышлыгы, булдыклылыгы белән таң калдырды. Яшьлегендә ут өертеп эшләгән апа 73 яшендә дә яшьләр белән бертигез дәрәҗәдә сарык йоны алып йөри.

– Узган ел Норлат авылында алты хатын 1029 баш сарыкның йонын 12 көндә алып чыктык, – дип шаккатырды ул. – Бер сарыкка 150 сум алабыз. Ул вакытта һәркайсыбыз 30 мең сум тирәсе акча эшләдек. Күрше-тирә авылларга еш йөрибез. Мөрәҗәгать итүчеләр елдан-ел арта. Ун ел элек башлаган идек без бу кәсебебезне.

Бригададагы иң өлкәне дә, барысын да алдан көйләп, оештырып торучысы да – Зинаида ханым.

– Калганнарыбыз яшьләр – 45–50 яшьлек хатын-кызлар, – ди ул. – Бик тырыш алар. Кишер Аксуында кишер, чөгендер алалар, Бик-Үти авылында җиләк-җимеш үстерү белән шөгыльләнүче фермерда эшлиләр. Анда җиләк-җимеш җыялар. Ике ел элек үзем дә бардым, тик хәзер йон гына алырга йөрим. Былтыр Шигали авылына дүрт хатын каз өмәсенә дә бардык. Каз саен 150 сум акча алдык. Бройлер йолкырга да барган булды. Безнең Чуаш Аксуы хатыннарына бер сүз әйтерлек түгел. Нәрсәгә тотынсалар, шуны булдыралар. Болай гына үзара да ярдәмләшәбез. Ир-егетләр дә авылда йортларны бергә, өмә белән күтәрәләр. Мин эш яратам. Гомер буе хезмәттә булдым. Хат ташыдым, өч малай үстердек, йортлар салдык. Сарык йонын алырга аеруча нык яратам. Әйе, акчасы да кирәк, ләкин рәхәт итеп эшлим.

Зөһрә САДЫЙКОВА

СЕЗНЕҢ АВЫЛДА БЕРДӘМЛЕК БАРМЫ?

Зөлфәт ИБРАҺИМОВ (Яшел Үзән районы Каратмән авылы):
– Терлекне күрше-күлән бергә җыелышып эшкәртәбез. Хәзер инде авылда башка күмәк эшләр юк. Печәнне дә түкләп кенә алып кайталар. Мунча, йорт бурасы күтәрү ише эшләрне төзүчеләр бригадасы килеп эшли.

Лилия КУПАЕВА (Әлмәт районы Бишмунча авылы):
– Безнең авылда бердәмлек бар әле. Кул алышып эшләү дигән күренеш яши. Алты-җиде хатын-кыз җыелышып, бер-берсенә өмәгә йөрешә. Без дә барырга тырышабыз. Ул – элек-электән килгән матур гадәт. Аны ничек тә бетермәскә иде әле. Ир-атлар да шулай йөри. Авылда, билгеле, кулы эшкә яткан, «кулы тәмле» булган берничә сугымчы бар.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА (Актаныш районы Иске Кадермәт авылы):
– Хәзер кешегә эшләү кимсенү санала. Өмәләр үтми, чөнки авылда узышу өстенлек итә. Элеккеге кебек бергә эшләп, ашап-эчүләр дә бетте. Бары тик акчага гына эшлиләр. Хатын-кызлар, эчәк юган, чиләк төбенә салып алып кайта кайтуын. Минем әни дә каз өмәләренә, эчәк юышырга йөри. Кеше белән аралашып кайту үзе бер рәхәт, дип бара. Аннан соң, авылларда нык, гайрәтле ир-атлар да бетте бит. Күпчелеге авылдан читкә китеп эшлиләр. Бу да аны таркатуга үз өлешен кертте.

Алисә САБИРОВА (Балык Бистәсе районы):
– Әти-әнинең эше булса, безгә, балаларына дәшә. Бу елларда, мәсәлән, кайтып, мал суябыз. Балалар, кияү-киленнәр кайтса, башка кеше кирәкми дә. Хәер, өмәгә дәшәрлек күршесе дә калмады хәзер. Авылда йомышчы кешеләр бар-барын, ләкин аларның өлкәнрәкләре эчүгә сабышып бетте. Эшләргә саулыгы, көче калмады. Яшьләр дә бар, тик халык аларның хезмәтен кыйммәтсенә.

Ландыш ҖИҺАНШИНА (Азнакай районы Чалпы авылы):
– Зур эшләрне туганнар җыелышып башкарабыз. Сугым булганда күрше Хәмит абый булышырга керә. Туганыбыз Марат абый трактор һәм таган белән килә. Терлек эчәген кодагыйлар, апалар юыша. Хәзер күпчелек авылларда шулай дип беләм. Иң элек ярдәмгә туганнар ашыга. Рәхмәт аларга.

ТҮР КЕМНЕКЕ – МЕНДӘР ШУНЫКЫ

ФАТИРГА КЕРГӘНДӘ ТӨСКӘ-БИТКӘ, МИЛЛӘТКӘ КАРАП ТОРМАЯЧАКЛАР

«Циан» торак эзләү турында белдерүләр хезмәте игълан урнаштыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертте. Хәзер фатирын арендага биреп торырга яисә сатарга җыенучылар белдерү текстында йортның булачак хуҗаларына карата дини, этник һәм раса буенча таләпләр куя алмаячак. Моны ксенофобия күренешләре, милләт һәм раса каршылыгы, этник дискриминациягә каршы чара дип аңлаталар. Социаль челтәрләрдә бу яңалыкка төрлечә җавап кайтаручылар булды: берәүләр моны уңышлы алым дип саный, кайсылары «Циан» порталын дискриминациядә гаепли. Үзгәреш нинди нәтиҗәгә китерер?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ни язганыңны белеп яз

Күз алдыгызга китерегез: сез фатир эзлисез. Белдерүләр карыйсыз, фатир тәкъдим итүчеләрнең таләпләрен өйрәнәсез. Ә анда «чисталык», «акчаны вакытында түләү», «эт-мәчесе булмасын» кебек мәгълүм таләпләр арасында «фатирда торучы сары чәчле булсын», «фәлән милләт вәкиле булмасын», «бары тик христиан дине тарафдары булсын» кебекләре дә бар. Ә сез сары чәчле дә, христиан дине тарафдары да түгел, өстәвенә арендаторга хуш килмәгән милләт вәкиле дә! «Циан», менә шушындый күренешләрне чикләү максатыннан, яңача эшләргә җыена да инде.

Порталның рәсми сайтында язылганча, яңа кагыйдәләр бу елның 1 декабреннән гамәлдә. Игълан авторлары фатир хуҗаларына карата өстенлекле таләп итеп милләт, дин, этник якларын (шул исәптән тән төсен дә) күрсәтә алмаячак. Хәзерге вакытка гамәлдә булган белдерүләрне исә 2022 елның февраленә кадәр төзәтергә була әле. Аннан соң портал хезмәткәрләре дискриминациягә китергән игъланнарны үзләре үк төзәтә башлаячак.

Тәкъдимне хуплаучылар да юк түгел. Әйтик, Хезмәт мигрантлары профсоюзы рәисе Ренат Кәримов: «Циан» – коммерциячел структура, ә коммерсантларның, закон чыкканын көтмичә, милли бүлгәләнешләргә юл куймавы мактауга лаек. Хуплыйбыз, бу тәкъдимнең ничек итеп башкарылачагын кызыксынып күзәтәчәкбез», – диде.

Сүз уңаеннан, «Циан» дискриминация мәсьәләсенә игътибар иткән берданбер хезмәт түгел. Ноябрьдә «Flats for Friends» торак эзләү төркеме җитәкчесе Марфа Некрасова да үзгәрешләр турында белдергән иде. «Барлык милләт, җенес, яшь, җенси билгеләнештәге кешеләр өчен», – диелгән иде бу төркемдә. Шунысы да бар: әгәр игълан авторы үз фатирында «билгеле бер категория кешеләр» булуын теләми икән, 499 сум күләмдә акча түләргә мөмкин. Тик күпләргә бу тәкъдим бик үк ошап бетмәде һәм төркемне түләүле дискриминациядә гаепләде.

Ачы тәҗрибә

Сәет Гарифуллин узган елның җәй айларында Казандагы ике бүлмәле фатирына кеше кертеп торырга уйлый. Әллә ни сайланып тормый, һүш китәрлек таләпләр дә куймый ул фатирның вакытлыча иясенә. Шулай итеп, фатирына берничә үзбәк егетен кертә. Соңрак исә таныш-белешләренең кисәтүләре рас килүгә инана.

– Аларны фатирга кертүем ачы тәҗрибә булып калды. Алар килешү таләпләрен үтәмәде. Бу даими кабатланып килде. Әйтик, беренчедән, фатир өчен акчаны вакытында түләмәделәр. Аннан, фатирда яшәүчеләр саны да килешенгәннән артыграк иде. Кыскасы, чын кунакханә! Чисталык ягы да аксады, – дип сөйләде Сәет. – Фатирга керүчеләрне эзләгәндә үк таләпләр куймадым, кем торуы мөһим түгел иде. Шулай да моңа игътибар итәсе калган.

Сәет әйтүенчә, торак-милек мәсьәләсендә «Циан» керткән үзгәрешләргә урын бар. Тик, рәсми рәвештә чикләнсә дә, асылда кеше барыбер шәхес үзенчәлекләренә игътибар итәчәк дип саный ул. «Шунысы да бар: гомуми караш, калыплашкан фикерләр безнең аңга шулкадәр кереп урнашкан бит инде хәзер. Күп кенә милләт вәкилләре моның өчен үзләре үк тырышты. Бәлки, торак эзләгәндә, махсус фильтр булдырыргадыр? Әйтик, «РФ гражданнары өчен», «читтән килгәннәр өчен» дигән бүлекләр ясарга. Милләтләр күп, төрле, аларның намуссыз вәкилләре аркасында башкалары зыян күрергә тиешме? Ватандашларының тәртипләре бик үк әйбәт булмаганга, алар гаепле түгел бит», – дигән фикердә Сәет.

Чикләүнең дә – үз чиге

Хокук белгече Ләйсән Халикова бу яңалыкны тәнкыйтьләр алдыннан, үзебезне башкалар урынына куеп карарга чакыра.

– Дискриминация – яхшы күренеш түгел. Билгеле, һәрбер милләт хөрмәткә лаек. Үзебез дә бит сәяхәт итәргә яратабыз, башка милләтләр яшәгән җирләргә барабыз. Үзебезне алар урынына куеп карарга кирәк. Начар мөнәсәбәт күрсәк, нинди рәк хисләр кичерер идек икән? Кешеләрне толерант булырга өндәр идем. Һәр милләтнең үз тормыш рәвеше, мәдәнияте, канына сеңгән үзенчәлекләре бар. Алар аерыла. Әйтик, кемдер бик кызу канлы, кайсылары салмак, тыныч. Тормышка карашыбыз да үзгә. Бер-беребезне аңларга кирәк. Аңлашылмаучанлыклар дискриминациягә китерә дә, – дигән фикердә ул.

Хокукый яктан караганда, чикләү әллә нинди үзгәрешләр бирмәскә дә мөмкин дип саный белгеч.

– Бәлки, фатирга керергә теләп шалтыратулар саны күп булыр дип уйларга буладыр, тик, икенче яктан караганда, фатир тәкъдим итүченең башында нинди дер кысалар бар икән, ул инде уеннан кире кайтмаска да мөмкин. Әйе, кемнеңдер алдап шалтыратуы, үзенең башка милләт вәкиле түгел икәнен әйтүе дә ихтимал. Тик очрашканда барысы да күренәчәк. Чикләүләр булмаган очракта, фатир тәкъдим итүченең дә, вакытлыча иясенең дә вакыты әрәм китәчәк. Аларга күбрәк йөрергә, элемтәдә торырга туры киләчәк. Бу милек мәсьәләсен катлауландырачак кына. Әйтик, безнең милләт вәкиле дә, башкасы да торган җирендә бик үк пөхтә-чиста, әдәпле булмаска мөмкин. Мин бит фатир өчен акча түлим, шулай булгач, ни телим, шуны эшлим дигән фикер була ала. Барысы да тәрбиягә бәйле. Әмма чикләүләр формаль рәвештә калса, дөрес булыр. Әмма ике якның да эшен арттыру ниятеннән эшләргә кирәкми, – диде Ләйсән Халикова.

Әле бит кешенең мөрәҗәгать итүчеләрнең теләсә кайсына ризалык белдермәскә дә хокукы бар. «Фатир – кешенең милке. Милкеңә өчен кайгырасың инде. Әйтик, ярты елга фатирга кертеп торасың икән, андагы мебельне бозулары, фатирны начар хәлгә китерүләре бар. Андый тискәре якларын дәүләт тә, «Циан» кебек сайтлар да үз өстенә алмый. Аның өчен хуҗасы җавап бирә», – дип искәртә белгеч.

Фатирга кеше кертергә җыенган кешеләргә кайбер киңәшләрне истә тоту зыян итмәс. Әйтик, иң элек, дөрес итеп килешү, акт төзергә. Биредә фатирның хуҗадан соң нинди хәлдә калуы күрсәтелә. Шулай ук бер-ике айлык аренда суммасын «залог» итеп алырга киңәш ителә. Бу үзенә күрә куркынычсызлык чарасы кебек. Шулай ук документларының күчермәсен соратып алырга да мөмкин.

Риэлтор Айдар Рәхимов фикеренчә, мондый чикләүнең бернинди дә мәгънәсен күрми, чөнки, аныңча, мондый проблема да ул дәрәҗәдә юк.

– Шәхсән мин, игълланнар сайтында «үзбәкләргә сатмыйбыз», «русларны гына кертәбез» ише дискриминация күренешләрен очратканым юк. Беренче ишетәм дияр лек. Башка хезмәттәшләрем нәкъ тә шушы тәкъдимне керткән «Циан»да «бары тик славян милләтеннән булган кешеләргә генә» дигән аерым игъланнарга юлыкканнары бар. Мин исә бу яңалыгы белән «Циан» үзенә карата игътибар җәлеп итмәкче дип уйлыйм. Милек мәсьәләләрендә мондый кысалар булырга тиеш түгел. Әллә нинди милләттән булсын, акча ягыннан отышлы икән, фатир иясе торагын кемгә дә сатып җибәрәчәк, – ди белгеч. – Әлбәттә, бик үзсүзле кешеләр бар. «Рус булмаган»нарга фатир сатмыйм, фәләннәрне кертмим дип уйлап, үзләренчә эшлиләр. Бервакыт миңа татар кызы мөрәҗәгать итте. Фатир алып, ипотека рәсмиләштермәкче иде. Фатир тәкъдим иткән ир-ат исә ипотекага ризалашмады, чөнки ул хәрам санала. Монда сүз ксенофобия турында бармый, күргәнегезчә, татар кешесе татарга да сатарга теләмәде әле.

Татар егетенең Мәскәүдә күргәннәре

Милләттәшебез, «Известия» газетасы корреспонденты Эльнар Байназаровка да бу арада фатир эзләү мәшәкатьләре белән очрашырга туры килгән. Эзләнү шактый озакка сузылган, фатир тәкъдим итүчеләрнең көйсезлекләрен дә күргән. Нәтиҗәдә күңеленә дә, кесәсенә дә хуш килерлек фатир тапкан ул. Мәскәүдә яшәүче яһүд гаиләсенең фатирына кергән, 40 мең сум түли.

– Исемнең тормышта ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын башыма да китермәдем. Фатир эзләгәндә, риэлторга шалтыратуым узган гомеремнең эчтәлеген сөйләүгә тиң иде: «Алло, исәнмесез, минем исемем – Эльнар, мин Казаннан, Мәскәү дәүләт университетын тәмамладым, журналист, миңа – 26 яшь, ялгызым гына яшим, өй хайваннары тотмыйм». Арабистика белән кызыксынуымны, «кайнар нокталар»да эшләвем турында, музыкаль белемем барлыгын әйтмим. Берсендә риэлтор: «Эльнар, ә сез ак тәнлеме? Фатир хуҗасы ак тәнлеләрне тели», – димәсенме. «Тели» дигән сүзендә нинди мәгънә ятканлыгын, кем белсен! Мин исә: «Сез татарларга каршымы әллә?» – дип сорадым. «Юк, юк, башка милләтләргә каршы түгелмен», – дип тезеп китте бу. Шунысы гаҗәпләндерде: ни өчен Татарстан, Кавказ, Башкортстан, Тыва, Хакасия, Алтайдан булган кешеләргә үз исеменнән оялырга туры килә икән? Нигә аның теге яисә бу милләттән булуы киртә-каршылык санала? Ни өчен бу фатир мәсьәләсендә дә калкып чыга? Шул ук «Циан»да гына да 50 мең сумнан артмаган бәягә фатирын биреп тору турында 4 меңгә якын игълан бар. Шуларның 1 меңнән артыгында «славяннар өчен генә» һәм «славян кыяфәтлеләр өчен генә» дигән таләпләр күрсәтелгән. Һәр дүртенче белдерү шундый дигән сүз бит бу, – дип сөйләде Эльнар.

«Циан»ның яңалыгын уңай күренеш буларак кабул иткән журналист. «Башлангыч этапта ук дискриминациягә юл куелмый. Очрашып күрешкәч, кешеләр фикерләрен үзгәртергә, йомшара төшәргә дә мөмкин әле. Дорфа кыланырга, «безгә сезнең кебекләр кирәкми» дияргә кыенрак. Интернеттагы ксенофобиягә юл куелмас, бу – беренче зур адым», – ди ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

17 декабрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Зөһрә САДЫЙКОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Югалткан исемне кайтарып буламы?

Мин 40 елдан артык авылда фельдшер булып эшләдем. 1991 елда фельдшер-акушерлык пункты җитәкчесе булдым. 1982–1983 елларда миңа «Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау отличнигы» дигән күкрәк билгесе бирелгән иде. Тик аны югалттым, бернинди документ та сакланмаган. Бу хакта хезмәт кенәгәсендә дә берни язылмаган. Әгәр «хезмәт ветераны» дигән исем булса, ташлама да билгеләрләр. Бу исемне кайтарып буламы?

Зәй районы
(исемем редакция өчен генә)

Эльмира Хужина, Зәй районының социаль яклау бүлеге җитәкчесе:
– Документларны яңартырга мөмкин. Әлеге күкрәк билгесе югалган булса, бу хакта кадрлар бүлегеннән язу (выписка) алырга кирәк. Анысы да юк икән, бу инде – кадрлар бүлегендә эшләүчеләрнең хатасы. Бу очракта хат авторына Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Фельдшер сәламәтлек саклау юнәлешендә эшләгән. Министрлыкта дәүләт бүләкләре алучыларның исемлеге булдырыла. Мондый исемне бирү турында карар булырга тиеш. Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы бары әлеге документлар нигезендә генә «хезмәт ветераны» исемен билгели ала. Алар безгә бу бүләкне яки «выписка»ны, стаж турында мәгълүматны тәкъдим итә. Документлар әзер булгач, Татарстан Хезмәт министрлыгы белән бергәләп «хезмәт ветераны» исеме бирү турында карар чыгарабыз.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат үзәге:
– Моның өчен авторга министрлыкның электрон почтасына яки интернет кабул итү бүлегенә исем-фамилиясе, эш урыны, хезмәт елларын күрсәтеп хат язарга кирәк. Әлеге мөрәҗәгатьтән соң министрлык Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы аша кирәкле мәгълүматларны соратачак һәм шуннан соң гына сезгә белешмә бирееп булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Безне ник Арчага йөртәләр?

Яман шеш белән авыручыларга ни өчен район хастаханәсендә, Чепья амбулаториясендә химия терапиясе алу мөмкинлеге юк? Моны бит һәр районда эшләргә мөмкин. Авыру кешегә еракка бару уңайсыз бит. Казан онкология үзәгендә урын юк та юк инде. Шул ук Кукмара, Әтнә, Саба, Балтач районнарын Арча районы хастаханәсенә җибәрәләр. Авырулар күп, чират көтәргә кирәк. Авыру кешегә һәр секунд кадерле.

САМАТОВ. Балтач районы

Газинур Дәүлиев, Балтач район үзәк хастаханәсе баш табибы:
– Бу – район күләмендә хәл ителә торган әйбер түгел. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының яман шеш белән авыручылар, химия терапиясе алучылар өчен булдырылган республика карары бар. Арча хастаханәсендә яман шеш бүлеге эшли. Тирә-як районнарда яшәүчеләр химия терапиясен шунда ала. Махсус онкологлар билгеләнгән. Алар бит барлык районнарда да юк. 4–5 кеше өчен генә мондый белгечләр тотып та булмый. Арчада зур чиратлар юк дип беләм. Кайбер кешеләрнең система куйдырыр өчен еракка барасы килми. Күпләр системаны үз район хастаханәсендә көндезге стационарга барып алу җайлы дип уйлый. Ләкин аның икенче ягын да карарга кирәк. Химия препаратлары организмга бик көчле тәэсир итә. Бу эшне теләсә кайсы табибка тапшырып булмый. Моның үз тәртибе бар. Шуңа күрә галимнәр, онкологлар бергә киңәшләшеп, республикада районара бүлекләр булдырылды. Район хастаханәсе яки Чепья амбулаториясендәге табиблар химия терапиясенә алынмый. Ни өчен дигәндә, онколог белгечлеге, лицензия, сертификатлары юк. Алар – гомуми практика табиблары.

Хат ташучы газетаны ник китермәгән?

«Ватаным Татарстан» газетасына язылган идем. Тик узган атнаның җомга саны килмәде. Ни сәбәпле китермәгәннәр икән?

Фәүзия НОГМАНОВА. Казан

Фучик урамындагы 34 нче почта бүлеге:
– Хат ташучы, газеталарны тараттым, диде. Ул санны тагын бер кат илтәчәк. Ул эшенә җитди карый, барысын да вакытында тарата.

Фикер

Нигә Шәүрәне Шура дип бозабыз?

Соңгы елларда күпләрнең чын татар исемнәре кушуы сөендерә. Гадәттә, рус, Европа халыкларыннан кергән исемнәрне катнаш никахтан туган балалар куша. Күптән түгел миңа бер оешмада булырга туры килде. 40 яшьләр тирәсендәге Шәүрә исемле хатынга бер хезмәттәше Шура, икенчесе Шурочка, өченчесе Александра дип дәшүләрен ишетеп, гаҗәпкә калдым. «Нишләп сез Шәүрәдән көләсез, аның исеме үзе кебек бик матур», – дигәч, тегеләр аптырап калды. Шул көннән башлап, аның исемен Шәүрә дип әйтергә сүз куештылар. Без исемне үзгәртеп дәшүләргә битараф, ник моңа бер дә борчылмыйбыз икән?

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА. Казан

Рәхмәт ишетү рәхәт

Игелегегез меңе белән кайтсын!

10 ноябрьдә йортыбыз янды. «Карактан кала, уттан юк», – дип белми әйтмиләр икән. Салкын көздә, гараж, мал абзарлары, сарайларыбыз янып бетте. Хәсрәтле вакытыбызда мәрхәмәтле кешеләрнең җылы сүзе, ярдәме безгә алга таба яшәргә көч бирде. Туганнарыбыз, Ташкичү авылы халкы бик булышты. Район башлыгы Ранис Камәртдиновның да ярдәмен тойдык. Фермерлар Фәнис Шәрәфетдинов, Салават Айзатуллин, Айрат Аллямов матди ярдәм күрсәттеләр.
Ульян өлкәсеннән Рәсүл хәзрәткә, Чувашиядән Мансурга, Шыгырданнан Наилгә, Кызыл Камышлыдан Дамирга, Батыр районы Озын Куак авылы кешеләренә, безгә ярдәм иткән мәчетләргә, исемнәре язылмыйча калган һәр кешегә чиксез рәхмәтебезне җиткерәсем килә. Шөкер, йортны торгызабыз. Безгә ярдәм иткән һәр кешегә Аллаһы Тәгалә савабын бирсен, үз игелегегез меңе белән әйләнеп кайтсын иде.

Ринас ЯФИЗОВ.
Буа районы Тимбай авылы

Сериалның вакытын күчереп буламы?

«Халык авазы» сәхифәсен көтеп алам. Халыкны борчыган сорауларны хәл итәргә булышуыгыз өчен рәхмәт. «Яңа Гасыр» каналында «Ай тулганда» дигән сериалны көндезге сәгать 12дә күрсәтәләр. Без бу вакытта өйлә намазын укыгач, карый алмыйбыз. Бик кызыклы, карыйсы килә. Дөрес, кичке 11дә аны янә кабатлыйлар. Тик бу вакытта йокларга ятабыз. Аның вакытын үзгәртеп буламы икән?

Фәһимә СӘГЫЙРОВА.
Дәрвишләр бистәсе

Редакциядән
«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры Илшат Әминов белән элемтәгә кердек, ул бу сорауны өйрәнәчәкләрен әйтте.

Җавапларны Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

«ТАТЭНЕРГОСБЫТ» БЕЛГЕЧЛӘРЕ КИҢӘШ БИРӘ

«Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең элемтә үзәгенә «акыллы» исәпләгечләр урнаштыру, алыштыру яки пломбалау буенча күп кенә сораулар килә. Иң еш очрый торган сорауларга җавап бирәбез.

– Исәпләгеч алыштырган өчен түләргә кирәкме?
Исәпләгечнең үзе өчен, аны урнаштырган, алыштырган һәм пломбалаган өчен кулланучыга түләргә кирәкми. Бу хезмәтләр бушлай күрсәтелә.

– Тикшерү вакыты чыккан исәпләгечне кайчан алыштырырга?
Тикшерү вакыты:
✓2020 елның апреленә кадәр чыкса, «Татэнергосбыт» исәпләгечне 2021 елның 31 декабренә кадәр алыштыра (тикшерә).
Исәпләгечне алыштыруга берничә көн кала сезгә шалтыратып, бу эшне башкару көнен һәм вакытын әйтәчәкләр.
✓ 2020 елның апреленнән соң чыкса, «Татэнергосбыт»:
– исәпләгечнең төгәл эшләү вакыты чыкканнан соң;
– кулланучы мөрәҗәгать иткәннән соң 6 ай эчендә хәл итәчәк.

– «Акыллы» исәпләгечне урнаштыргач, күрсәткечләрнең шуннан тапшырылуын ничек белергә?
– «Акыллы» исәпләгечне файдалануга тапшыруга рөхсәт итү актын төзегәндә, сезгә исәпләгечнең «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең «акыллы» учет системасына тоташтырылуы турында хәбәр бирү ысулын сайлап алу тәкъдим ителә. Моның өчен актта мобиль телефон номерын яки үзегезнең электрон почта адресын күрсәтергә кирәк.
Шуннан соң сайлап алынган ысул белән сезгә исәпләгечне «акыллы» учет системасына тоташтыру турында хәбәр ителеп, күрсәткечләр дистанцияле рәвештә тапшырыла башлаячак. Алга таба җәмгыятьнең «акыллы» учет системасына тоташтырылу турында квитанциянең кире ягына тиешле билдеү урнаштыру юлы белән хәбәр итү күздә тотыла.

Хөрмәтле клиентлар! Сорауларыгыз булса, сез элемтә үзәгенең бушлай телефоны (8-800-200-25-26) аша оешма белгечләренә мөрәҗәгать итә аласыз.

13 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.40 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 00.00 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». Зәйнәб Фәрхетдинова 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Реальная экономика» 12+
22.30 «Вызов 112» 16+
00.50 «Соотечественники» 12+
01.15 «Черное озеро». Всадник по имени Смерть. Банда Шакура 16+
01.45 «Память сердца» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.00, 04.15 «Башваткыч» 6+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.05, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. Даниил Страхов. «ЗНАХАРЬ». Новые серии (S) 16+
23.30 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.00 «Познер» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу. 12+
14.55 Премьера. Алёна Спивак, Леонид Кулагин, Дмитрий Блохин, Валерий Сторожик. «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. Анна Ковальчук. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-21» 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 «В ЗОНЕ РИСКА» 16+
04.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 16.00, 22.35 Новости
06.05, 18.20, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.35, 01.40 Спец. репортаж 12+
09.25 «ПРОЕКТ А» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 Зимние виды спорта. Обзор 0+
13.45 Все на футбол! Жеребьевка еврокубков. Прямой эфир
16.05 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
17.00 Хоккей. Гала-матч «Связь поколений» 0+
18.55 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. «Сочи» – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция.
21.00 «Громко». Прямой эфир
22.05 Тотальный футбол 12+
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Рома» – «Специя». Прямая трансляция
01.20 «Есть тема!» 12+
01.55 «ПАРЕНЬ ИЗ ФИЛАДЕЛЬФИИ» 16+
03.30 Новости 0+
03.35 Гандбол. Чемпионат мира. Женщины. Трансляция из Испании 0+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Игорь Лифанов, Роман Курцын. «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. СИМБИРСКИЕ МОРОЗЫ» (S) 12+
23.40 «СССР. Крах империи». Фильм Владимира Чернышева 12+
03.30 Детективный сериал «ГРЯЗНАЯ РАБОТА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «Реальная мистика» 16+
07.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.55 «Давай разведёмся!» 16+
11.10 «Тест на отцовство» 16+
13.20 «Понять. Простить» 16+
14.25 «Порча» 16+
16.00 «Знахарка» 16+
17.50 «Верну любимого» 16+
19.00 «НА ТВОЕЙ СТОРОНЕ 2» 16+
22.55 «Кризисный центр» 16+
03.35 «Реальная мистика» 16+
04.25 «Тест на отцовство» 16+
06.05 «Домашняя кухня» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «ОПЕРАЦИЯ «ГОРГОНА» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня. 16+
09.20, 01.25 «ЧЕЛОВЕК-АМФИБИЯ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Оружие Победы». Док. сериал. 12+
13.40, 14.05 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Спец. репортаж» 16+
18.50 «Конструктор №1. История ОКБ Туполева». Док. сериал. Фильм 1-й 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №83» 16+
20.25 «Загадки века». Док. сериал. «Агент «Этьен» – охотник за авиационными секретами» 12+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «КРИМИНАЛЬНЫЙ КВАРТЕТ» 16+
03.00 «Афганский дракон». Док. фильм 12+
03.30 «Москва фронту». Док. сериал. 16+
03.50 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК» 16+

14 декабрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 14.45, 17.30, 22.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
09.35 «Акыл баттл» 0+
10.00, 23.30 «ОРЛОВА И АЛЕКСАНДРОВ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «АЙ ТУЛГАНДА» 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.30 Новости Татарстана 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
17.00, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы»16+
20.00, 22.30 «Вызов 112» 16+
20.15 «Год родных языков и народного единства в РТ» 12+
21.00 «Черное озеро» 16+
00.20 «Видеоспорт» 12+
00.45 «Соотечественники». Юнус Ахметзянов. Повар национального масштаба 12+
01.10 «Черное озеро». Всадник по имени Смерть. Конец легенды 16+
01.35 «Память сердца» 12+
01.50 «Не от мира сего…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.00, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40, 20.30, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
15.20 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.00, 00.15 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
02.45 «Караоке татарча» 6+
03.25 «Онытa алмыйм» 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.15, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское / Женское» 16+
17.00 «Время покажет» с Артемом Шейниным 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ЗНАХАРЬ». Новые серии (S) 16+
23.35 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 «Леонид Броневой. «Заметьте, не я это предложил…» 12+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.0,0, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «КУЛАГИНЫ» 16+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-21» 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «В ЗОНЕ РИСКА» 16+
04.00 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.50, 12.30, 15.50, 19.05 Новости
06.05, 19.55, 22.30, 00.55 Все на Матч! Прямой эфир
08.55 Специальный репортаж 12+
09.15 «ПРОЕКТ А 2» 12+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 Все на регби!
13.05 «КУЛАК ЛЕГЕНДЫ: ВОЗВРАЩЕНИЕ ЧЭНЬ ЧЖЭНЯ» 16+
15.15, 15.55 «УНИВЕРСАЛЬНЫЙ СОЛДАТ» 16+
17.25, 19.10 «ПОЕЗД НА ЮМУ» 16+
20.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Штутгарт» – «Бавария». Прямая трансляция
22.55 Волейбол. Лига чемпионов. Мужчины. «Маасейк» (Бельгия) – «Динамо» (Москва, Россия). Прямая трансляция
01.30 «Есть тема!» 12+
01.50 Мысли как Брюс Ли. «Будь водой». Док. фильм 12+
03.40 Новости 0+
03.45 Волейбол. Лига чемпионов. Мужчины. «Локомотив» (Россия) – «Кендзежин-Козле» (Польша) 0+
05.30 «Голевая неделя» 0+

НТВ

05.00 «МУХТАР. НОВЫЙ СЛЕД» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. СИМБИРСКИЕ МОРОЗЫ» (S) 12+
23.40 «СССР. Крах империи». Фильм Владимира Чернышева 12+
02.30 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» (S) 16+
03.30 Детективный сериал «ГРЯЗНАЯ РАБОТА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «Реальная мистика» 16+
07.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.55 «Давай разведёмся!» 16+
11.10 «Тест на отцовство» 16+
13.20 «Понять. Простить» 16+
14.25 «Порча» 16+
16.00 «Знахарка» 16+
17.50 «Верну любимого» 16+
19.00 «НА ТВОЕЙ СТОРОНЕ 2» 16+
23.00 «Кризисный центр» 16+
03.40 «Реальная мистика» 16+
04.30 «Тест на отцовство» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Специальный репортаж» 16+
09.35, 02.10 «СТРЕЛЫ РОБИН ГУДА» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Конструктор №1. История ОКБ Туполева». Док. сериал. Фильм 2-й 16+
19.40 «Легенды армии». Василий Порик 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «20 ДЕКАБРЯ» 12+
03.25 «Москва фронту». Док. сериал 16+
03.45 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 13–19 ДЕКАБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04) Акча мәсьәләсендә хәлләрегез бермә-бер яхшырыр. Отышлы гына бәядән шәп әйбер сатып алырга, акча җыя башларга яки кредитны капларга мөмкинсез. Ләкин туганнар белән үзара мөнәсәбәтләрне бераз сыныйсы бар. Иң элек сез юл куегыз: шулай икән, барысы да бик тиз көйләнер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05) Тормышка карашыгыз турында уйланыр өчен әйбәт чор. Саксызрак сүзегездән үпкәләгән бер танышыгыздан гафу итүен сорарга кирәк булыр. Ниндидер бер мөһим әйберне онытып җибәрү куркынычы бар: шуңа күрә барысын да язып куярга кирәк.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06) Тормыштагы четерекле генә бер мәсьәләнең очына чыгу көч-куәтегезне арттырып җибәргәндәй итәр. Кайда гына булмасын, артык сүз ычкындырырга тырышмагыз, юкса уңайсыз хәлдә калуыгыз бар. Эшегезне сыйфатлырак башкарырга тырышыгыз, җитәкчегездән шелтә алу ихтималы юк түгел.

КЫСЛА (22.06 – 22.07) Якыннарыгыз киңәшен колак читеннән генә уздырып җибәрмәгез, юкса үкенергә мөмкинсез. Акча мәсьәләсе итәктән тарта башладымы? Хафаланмагыз, тиздән әйбәт кенә керем алачаксыз. Атна ахырында кибетләрдә саграк булыгыз: Яңа ел алды ташламасы дигәнгә ышанып, өч тиенлек яраксыз әйбер сатып алмагыз!

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08) Соңгы көннәрдә үзегезнең төн йокысын качырган бер мәсьәлә, ниһаять, әйбәт кенә хәл ителер. Тик сөеклегез белән уртак фикергә килү авыррак булыр. Кызып китмичә генә, ягымлы гына сөйләшергә тырышыгыз – шулай икән, дөнья бик тиз тынычланыр.

КЫЗ (24.08 – 22.09) Атна башында үзегезне әйбәт кенә сюрприз көтә. Шулаен-шулай, тик аннан соң кайбер сорауларның килеп чыгуы гына… Аның каравы эштә ялтырап алу өчен искиткеч шәп мөмкинлек чыгар. Бу хәл җитәкчегез бик ошар һәм хезмәт хакыгызда да чагылыш табар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10) Күптәнге бер планыгызны тормышка ашырырсыз. Шулай итеп, үзегезнең чын сәләтегезне дә күрсәтә алырсыз. Кайбер көнче адәмнәргә бу ошамас. Мондыйларны күрмәмешкә салышыгыз – шулай икән, алар бик тиз тынычланыр.

ЧАЯН (24.10 – 22.11) Яңа кешеләр белән танышып, алдагы тормышыгыз өчен шәп кенә мөмкинлекләргә юл ачарсыз. Көнкүреш техникасын сатып алу өчен уңайлы чор – бәясе дә «тешләмәс», сыйфаты да сынатмас. Ял көннәрендә күңелегезгә сары май булып ятардай яңалыклар ишетерсез.

УКЧЫ (23.11 – 21.12) Көч-куәтегез ташып торганлыктан, эшкә бик каты керешерсез. Шуның аркасында хата ясап ташлау, аннан инде җитәкчегезнең канәгатьсез йөзен күрү куркынычы бар. Атна уртасында сәламәтлек борчып алырга мөмкин. Нишләтәсең, салкын тидерүләр сезоны бит…

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01) Искиткеч уңайлы чор: максатка ирешү өчен бер адым ясау да җитә! Ләкин шундый җиңеллектән башыгыз әйләнеп, уяулыкны җуярга мөмкинсез. Шуны истә тотып, җәмәгать урыннарында акча-мазар югалтудан сак булыгыз.

СУКОЯР (21.01 – 19.02) Яңа чор күңелегезгә хуш килердәй хәлләр, куанычлы хәбәрләр белән куандырыр. Акча мәсьәләсенең итәктән тартмый башлавы гына ни тора! Ләкин танышларыгыз арасында үзегезгә көнләшеп караучылар пәйда булырга мөмкин. Берни аңламаганга сабышып, алар белән дустанә сөйләшергә тырышыгыз. Юкса…

БАЛЫК (20.02 – 20.03) Сөеклегез үзегезне гаҗәпләндерү катыш сөендерер. Бик мөһим бер эшегезне башкарып чыгу өчен искиткеч яхшы шартлар пәйда булыр. Балаларыгыз матур гына яңалыклары белән уртаклашыр.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Саба муниципаль районы Советы, башкарма комитеты, якташыбыз, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме **Азат Гыйльмулла улы ӘХМӘДУЛЛИН** вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең якыннары һәм туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

«БАЛАЛАР КОРОНАВИРУСНЫ АВЫРРАК КИЧЕРӘ БАШЛАДЫ»

Коронавирусның яңа штаммы барлыкка килгәч, балалар бу чирне авыррак кичерә башлаган. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының инфекцияле авырулар буенча штаттан тыш белгече Владимир Чуланов шулай дип белдергән. Белгеч сүзләренә караганда, соңгы арада балалар арасында коронавирусны бернинди билгеләрсез генә уздыручылар да очрый башлаган. Бу нәрсәсе белән куркыныч? Балада коронавирус икәнлекне нинди билгеләр буенча чамаларга?

11 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе педиатры, Татарстанның атказанган табибы Гөлназ АЗИЗОВА белән әнә шул сорауларга җавап эзләдек.

:: Гөлназ Хәйдәровна, яңа штамм аркасында балалар коронавирусны авыррак кичерә башлады, диюләре дөреслеккә туры киләме?

– Әйе, бу, дөрестән дә, шулай. Вирус мутацияләнеп тора. Балаларның иммунитеты аңа каршы тора алмый. Хәзер боларга башка төр сезонлы вирусլы инфекцияләр дә өстәлде. Шул рәвешле хәзер балалар чирне авыррак кичерә. 1 яшькә кадәрге сабыйлар аны бигрәк тә авыр уздыра. Өч яшьтән алып 14 яшькә кадәрге балалар коронавирусны чагыштырмача җиңелрәк үткәрә. Ковид аларда бернинди билгеләрсез генә дә узарга мөмкин. Шул ук вакытта әлеге төркемгә кергән балалар бу чирне яңашәдәгеләргә дә йоктыра ала.

:: Олылардан аермалы буларак, балаларда коронавирус нинди билгеләр белән уза?

– Коронавирус йоктырган баланың температурасы еш күтәрелә. Әмма ул артык югары булмый. 37,2–37,9 градус тирәсендә тирбәлә. Бала бертуктаусыз йөткерә. Башка вируслы инфекцияләрдән аермалы буларак, коронавирус вакытында баланың борынына томау төшми. Ковид вакытында балада эч китү, косу кебек билгеләр дә күзәтелергә мөмкин. Тәнентә тимгелләр дә чыга ала. Соңгылары, гадәттә, бала чирнең бик авыр формасы белән авырганда күзәтелә. Сабыйның әйләнә-тирәсендә ковид белән авырган кешеләр булса, һичшиксез, баланы да тикшерергә кирәк. Бу очракта табиб өйгә килеп анализ ала, өч көн эчендә нәтиҗәсе әзер дә була.

:: Сез телгә алган билгеләр арасында кайсы иң куркыныч санала?

– Йөткерү, тын кысылу, сулаганда сызгырган тавыш чыгу коронавирус йоктырган балада күзәтелгән иң куркыныч билгеләр санала. Бала ярсыганда температура бик тиз күтәрелә. Тәнне көзән җыеру, тире астына кан саву кебек билгеләр дә ата-ананы пошаманга салырга тиеш. Андый чакта баланы кичекмәстән хастаханәгә салырга кирәк.

:: Бала коронавирус белән авырып терелгәннән соң да табиб күзәтүе астында торырга тиешме?

– Коронавирус белән авырган балалар педиатрда исәптә тора. Табиб андый балаларны ай дәвамында тикшерә. Моннан тыш алар пульмонологта да исәптә тора. Балага прививка ясату-ясатмау мәсьәләсе исә иммунолог рөхсәтеннән соң гына хәл ителә.

:: Коронавирус белән авырып терелгән балалар арасында өзлегү очраклары еш күзәтеләме?

– Коронавирус белән авырып терелгән балада еш кына ярсучанлык, гел елау, тиз ару кебек билгеләр дә күзәтелергә мөмкин. Бу очракта баланы неврологка күрсәтергә киңәш итәр идем. Ата-анага психолог белән киңәшләшеп алсалар да артык булмас. Коронавирус белән авырган бала, терелгәннән соң ике атна узгач кына, бакчага, мәктәпкә бара ала.

:: Баланың ковид йоктыруын алдан кисәтеп буламы?

– Моның өчен гади генә кагыйдәләрне истә тотарга кирәк. Иң беренче чиратта баланың коронавирус белән авырган кеше белән аралашуын чикләргә кирәк. Гигиена таләпләрен үтәү дә зарур. Теләсә кайсы вируслы авыруны кисәтү өчен иң беренче чиратта үтәлергә тиешле кагыйдә бу. Чир котырган чорда кеше күп җыела торган урыннарны да читләп үтүең хәерле. Бала йөргән белем бирү оешмасындагы балаларның сәламәтлеге дә даими рәвештә контрольдә тотылырга тиеш.

БАЛАЛАРДА КҮП КЕНӘ ЧИРЛӘР НИНДИ БИЛГЕЛӘР БЕЛӘН УЗА?

Билгеләр	Covid-19	Грипп	ОРВИ	Аллергия
Югары t°C	еш	еш	кайчак	юк
Хәлсезлек	еш	еш	кайчак	кайчак
Ютәл	еш	еш	еш	кайчак
Төчкерү	хас түгел	юк	еш	еш
Буыннар авырту	кайчак	еш	сирәк	юк
Борынга томау төшү	сирәк	кайчак	еш	еш
Тамак авырту	кайчак	кайчак	еш	юк
Эч китү	еш	кайчак	юк	юк
Баш авырту	кайчак	еш	сирәк	кайчак
Тын кысылу	кайчак	юк	юк	еш
Ис сизмәү, тәм тоймау	кайчак	кайчак	юк	юк

Сорау – җавап

Экспресс диета ничә килограмм ташлата?

Яңа ел алдыннан бераз ябыгасы иде. Артык килограммнарны тиз арада юкка чыгарырга ярдәм итә торган берәр ышанычлы экспресс диета киңәш итмәссезме икән? Аның белән ничә килограмм авырлыкны ташлап була?

Алсу ВАФИНА.
Казан

Сорауга табиб-терапевт, гастроэнтеролог Индира ГЫЙМАЛТДИНОВА җавап бирә:

– Шәхсән мин үзем экспресс диеталарга каршы. Мондый исуլ белән ябыккан кешенең организмын кабат элеккеге халәтенә кайтару бик авыр. Рационлагы калория күләме чамадан тыш кимегәч, организм йончый, әчке органнар дөрес эшләми башлый. Экспресс диеталардан могҗиза көтүчеләр бик нык ялгыша. Әлеге диета вакытында кеше калорияләргә кытлык кичерүе, физик активлыкны арттыруы хисабына гына ябыга.

Шпора үзәккә үтсә...

Аяк үкчәсендә шпора булган кешеләргә түбәндәге ысулның ярдәме тими калмас. Яңа салынган йомырканы стаканга салып, өстенә 100 г аш серкәсе агызырга һәм шул катнашманы караңгы, салкынча урынга куярга кирәк. 3–4 көн торганнан соң йомырканы серкәдән алып, аның юка элпәсен тишеп, агын агызасы. Ә йомырканың сарысын аерым савытка салып, күбекләнгәнче болгатырга кирәк. Аңа 100 г скипидар (ылыслы агач сагызыннан ясала, даруханәдә сатыла) һәм стакан төбендә калган серкәле утырманы аз-азлап кына куша барып, барысын бергә яхшылап болгатасы. Әзер булган катнашманы кара тәстәгә шешәгә агызып, караңгы урынга сакларга куярга кирәк.

Шпораларны кич белән дәваласаң яхшырак. Моның өчен иң элек мөмкин кадәр күбрәк диңгез тозы салып эретелгән 0,5 л су әзерләргә кирәк. Диңгез тозы булмаган очракта аш тозы кулланырга да ярый. Тоз эреп беткәч, шул җылы тозлы су белән авырткан урыннарны юып, сөлге белән яхшылап корытырга, аннары әзерләнгән катнашманы болгатканнан соң сөртергә кирәк. Катнашманы төнгә шпораларга сөртеп, йон тукыма белән капларга киңәш ителә.

Абау!

Помидор ковидтан саклый

Коронавирусны һәм салкын тиюне кисәтүче иң яхшы яшелчә помидор икән! Илкүләм диетологлар һәм нутрициологлар ассоциациясе әгъзасы Наталья Круглова Sputnik радиосына биргән әңгәмәсендә шулай дип белдергән. Белгеч сүзләренә караганда, помидорда организм өчен файдалы матдәләр, шул исәптән иммун күзәнәкләрне активлаштырырга сәләтле көчле антиоксидант — ликопин бар. «Ликопин организмны йөрәк-кан тамырлары авырулары, яман чир китереп чыгарырга мөмкин булган иркекле радикаллар йогынтысыннан саклый. Ликопин ярдәмендә иммунитетның саклагыч күзәнәкләре активлаша», — ди ул.

Сөт гомерне озайта

Рединг университеты галимнәре сөтнең гомер озынлыгын арттыруын ачыклаган. Көненә ким дигәндә бер стакан сөт эчү организмдагы холестерин һәм ишемия авыруы барлыкка килү куркынычын 14 процентка киметә, ди белгечләр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

БЫЕЛГЫСЫ ҮТКӘНДӘ КАЛСЫН

Яңа елга кадәр аз гына вакыт калып бара. Күпләр әлеге бәйрәмне яңа тормыш башлангычы буларак та кабул итә. Шуңа күрә Яңа елны ыгы-зыгыдан түгел, канәгатьлек хисе белән башлап җибәрү өчен кайбер эшләргә бу елда нокта куюың хәерле. Бәйрәм алдыннан төгәлләп өлгерергә кирәкле эшләр хакында белеп тору беркемгә дә зыян итмәс.

• Гафу итегез һәм гафу утенегез

Үпкә – бары үзебезгә генә зыян сала торган хис. Әлеге эмоциональ йөк белән киләсе елга керергә тырышмагыз. Әгәр берәр кешенең хатерен калдырсагыз, шулай ук гафу сорарга онытмагыз. Менә күрерсез, гафу иткәннән яки гафу үтенгәннән соң, күңел тынычлыгы һәм рәхәтлек тоярсыз.

! Үпкә хисеннән арынуның бер яхшы ысулы бар: ул – үпкәләткән кешегә хат язу. Анда сезне үпкәләткәннән соң үзегезне ничек хис итүегез, ниләр кичерүегез турында языгыз. Ахырда аны гафу итүегез турында да язарга онытмагыз . Шулай ук гаебегез булса, аннан гафу итүен сорагыз. Хатны җибәрү мәҗбүри түгел.

• Дус-туганнар белән очрашыгыз

Әллә ничә ел очрашырга сүз куешсагыз да, һаман очраша алмаган дус-туганнарыгыз бардыр. Шалтыратып, очрашу турында сөйләшегез һәм әлеге очрашуны «кайчан да булса бер очрашырбыз әле» дип тагын кичектермәгез.

• Бурычларыгызны кайтарыгыз

Моңа кайтармый йөргән акчалата бурычлар, онытылган шарф яисә китап ише әйберләр дә керә. Яңа елга кадәр булдыра алганча барлык бурычларыгыздан арынырга, аз гына калган кредитларыгызны түләп бетерергә тырышыгыз. Бурычлы булмаудан да рәхәт нәрсә юк бит ул!

• Өегезне җыештырыгыз

Җыештыру, тәртипкә китерү – бигрәк тә мөһим гамәл. Яңа ел алдыннан өегездә, кием шкафларыгызда, телефон яисә ноутбугыгызда тәртип урнаштырсагыз яхшы булыр. Киелми торган кием, кулланылмаган савыт-саба, урын-җирләрне ташларга яки мохтаҗларга бирергә мөмкин.

• Ел буе кичектергән эшне тәмамлагыз

Әллә кайчаннан кулыгыз җитми йөргән эшнең очына чыгып куйсагыз да яхшы булыр. Ремонтны тәмамларга, эштәге хисапларның очына чыгарга яки сессияне тапшырырга нәкъ менә кулай вакыт. Киләсе елда яңа мөмкинлекләр ачылсын өчен, сезне борчып торган эшләрегезнең берсен генә булса да тәмамлап куегыз.

• Узып баручы елга анализ ясагыз

«Нәрсәгә кирәк инде бу йомгак ясап торулар?» – дисәгез, аның берничә сәбәбе бар. Бу узып баручы елның сезнең өчен ничек узганлыгын аңлау өчен кирәк. Сезнең белән быел нинди күңелле һәм сезне чыгырдан чыгарган хәлләр булды? Бу тормышыгыздагы үсешне бәяләү өчен дә кирәк. Хыялыгызга ни дәрәҗәдә якынлаштыгыз? Горурланырлык яңа сәбәпләр булдымы? Әлеге сорауларга җавап бирү сезгә үзегезнең «йомшак» якларыгызны күрү һәм киләсе елда нәрсә өстендә эшләргә кирәклеген аңлау өчен кирәк.

• Киләсе елга максатлар языгыз

Кәгазьгә язылган максатларның чынга аша торган гадәте барлыгын белә идегезме? Барлык максат-хыялларыгызны дәфтәргә язып куегыз. Алар тормышка ашсын өчен, аны яздым да оныттым дияргә кирәкми. Максат һәм хыяллар исемлеген күз алдына куеп, чынга ашканнарын сызып бару киңәш ителә. Аларны сызгандагы канәгатьлек хисен тоюдан да рәхәт нәрсә юктыр!

• Бүләкләрне алдан алып куегыз

Дус-туганнарга бүләксез нинди Яңа ел инде ул?! Шуңа күрә бүләк бирәсе кешеләрегезнең исемлеген төзегез. Әлбәттә, үзегез турында да онытып җибәрмәгез. Яңа матур кием яки күптән кызыгып йөргән әйберегезне алыгыз. Якыннарыгызга бүләкләрне бәйрәмгә 2–3 көн кала түгел, ә нәкъ менә хәзер алсагыз яхшы булыр.

• Каникулны алдан планлаштырыгыз

Каникул диванда ятып, ашап-эчеп кенә үтмәсен өчен, аны алдан планлаштырсагыз яхшы булыр. Күбрәк актив ял итү турында уйлагыз. Кайда тау шуарга, тимераякта җилдерергә була соң? Дуслар, балалар һәм әти-әниләр белән бергә саф һавада күңелле итеп уздырылганяллар сәламәтлегегез өчен дә файдага булыр.

Белеп тор!

Алдан хәстәрен күр

Яңа ел алдыннан кибетләрдә халык күп йөрү сәбәпле, коронавирус йоктыру куркынычы арта. Бәйрәм яллары авырып узмасын өчен, кеше күп булган урыннардан читтә йөрергә тырышыгыз. Белгечләр исә бәйрәмгә кадәр бозылмый һәм бәясе артырга мөмкин булган ризыкларны алдан алып куярга киңәш итә.

Уылдык, зәйтүн җимешенә Яңа ел бәйрәме алдыннан бәяләр артырга мөмкин. Аларны хәзер алып куйсагыз да берни булмаячак. Катырылган балык, креветка, шулай ук борчак, кукуруз, башка төр консерваларны, кәнфит һәм каты сырны хәстәрләп куйсагыз да, бер эшегез бетеп торачак.

Остаханә

Оекбаштан – Кар бабай

Кирәк була: *ак һәм төрле төстәге оекбашлар, ак җеп, дөге, төрле төстәге төймәләр, җилем.*

Оекбашларны үкчәсе янынннан кисабез. Аннары аның аскы өлешен алып куеп торабыз. Өске ягын әйләндереп, җеп белән эчке яктан бәйлибез.

Оекбашның уң ягын әйләндерәбез һәм эченә коры дөге тутырабыз. Резинкасына кадәр тутырганнан соң, бераз гына кысып бәйләп, дүгәле оекбашны Кар бабай рәвешенә китерәбез. Иске оекбашлардан башлык, шарфлар ясап, Кар бабайны киендерәбез, төймәләр белән бизибез. Ясалма күз һәм борын ябыштырабыз яисә фломастер белән ясыйбыз. Әлеге уенчыкны ясаганда балалар бик яратып булыша. Аның белән өйне яки чыршы төбен бизәргә мөмкин.

Хуҗабикәгә

✓ Аш бүлмәсендә кулланыла торган сөлгеләрне юар алдыннан серкәле җылы суга салып тотсагыз, тизрәк юылыр һәм бик яхшы чистарыр.

✓ Плитәдәге май табына тоз сипсәгез, ул җайлырак чистартылыр.

✓ Чисталык хакына бер лимоныгызны кызганмагыз. Аш бүлмәсендә кулланыла торган куна һәм угычны әллә нигә бер булса да урталай бүленгән лимон белән сөртеп алыгыз. Ул күзгә күренмәс бактерияләр үрчүдән саклый.

Тәмле булсын!

ӘФЛИСУНЛЫ ҮРДӘК

Лилия ГАЛИӘХМӘТОВАдан үрдәк пешерү рецепты

Бер көн алдан үрдәкне бер кап тоз болгатылган салкын суга салып куябыз. Ул үзенә җитәрлек күләмдәге тозны гына сеңдерәчәк.

Икенче көнне шул үрдәкне алып, эченә бер туралган әфлисун, дүрткә бүленгән ике яшел алма, кара җимеш салып таякчыклар белән «тегеп» куярга. Үрдәк тышына, лимонны сыгып, шуның согын сөртергә. Аннары җиңсәгә тыгып, 1,5–2 сәгать сүрән утта пешерергә. Бик тәмле була!

ХӘРАМ МАЛ МИХНӘТЕ БАЛАГА ДА ҖИТӘ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Җәннәткә кермәүчеләр арасында минем товарым яхшы дип алдалап сатучы, табыш артыннан куучы сәүдәгәрләр торачак», – диелә. Ялган юл белән акча эшләргә теләүчеләр элек тә булган, хәзер дә җитәрлек. Кеше алдап акча эшләүчене нинди җәза көтә?

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән шул хакта сөйләштек.

:: Рөстәм хәзрәт, соңгы арада алдап акча эшләүнең нинди генә ысулларын күрергә туры килми. Халык ике көннең берендә мошенниклар, сатучылар тарафыннан алдана. Мондый күренешләр арту нәрсәсе белән куркыныч?

– Хәзер күпләрнең тиз һәм җиңел юл белән байыйсы килә. Әмма шул ук вакытта адәм баласы моның канунга каршы килгән, дөрес юл, дөрес гамәл түгел икәнлеген дә аңлый. Шул рәвешле алдалап акча эшләү юлына баскан кеше күңел тынычлыгын да югалта. Ул һәр нәрсәдән, һәр ишек шаку, шалтыратудан курка башлый. Даими рәвештә мондый халәттә яшәү аркасында, кеше тормышның, тапкан малының төмен белми башлый. Кеше алдау, икенче төрле әйткәндә, мошенниклык диндә монафыйклык дип йөртелә. Хәрам юл белән акча эшләүче шушы кешенең күңелен пәрдә каплый, ул чынбарлыктан аерыла, яхшылыкны аңламый башлый. Ялган аша кәсеп кылу йөрәкне шулкадәр томалый: киләчәктә ул үзенә дөрес юлны тапмаска, кешенең нәсыйхәтенә колак салмаска мөмкин. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Хәрам белән үскән тән кисәге хәрамгә, әшәкелеккә тартачак һәм җәһәннәм аша узачак», – диелә. Шуңа күрә ялганлап акча эшләргә теләгән кеше балалары турында да уйларга тиеш. Картлык көндә ул әнә шул баласы кулына калачак. Яманлык, алдашуны күреп үскән баладан киләчәктә нәрсә көтәргә?

:: Кибетләрдә бер үк товарны бүген – бер, иртәгә икенче төрле бәядән сату очраклары да еш күзәтелә. Моны да хәрам юл белән акча эшләргә маташу дип бәяләргәме?

– Арттырып сатуның үзенең кагыйдәләре бар. Бу очракта монополизм, ягъни үз дәрәҗәң белән сәүдә мәйданыннан башкаларны кысып чыгарып, үзеңнең товарыңны гына кертеп, арттырып сату хәрам дип санала. Әгәр ул иркеле базар һәм анда син дә, күршең дә үз товарын кертә икән, син үз товарыңа, үз хезмәтеңә бәяне үзең куясың. Бу гөнаһ саналмый. Әмма монда бер шарт бар. Товарның бәясе сатучылар белән үзара алдан килешеп арттырылмаган булырга тиеш.

:: Ялганлап хәер сорашучы гөнаһлымы? Аларга биргән хәер савап буламы?

– Әгәр кеше аның чынлыкта мохтаҗ булмый торып хәер сорашуын белмичә хәер бирсә, ниятенә күрә аңа әҗер-савабы булачак. Бу кеше изгелек эшләргә ниятләгән бит. Әмма шунысы да бар. Сәдаканы биргәч, син аның кайсы юлга китүе өчен җаваплы да буласың. Әйтик, ул тыелган оешмалар эшчәнлеге өчен дә тотылырга мөмкин бит. Шуңа күрә сәдаканы бирер алдыннан аны кемгә бирүеңне алдан тикшерсәң, хәерлерәк. Кеше акчага мохтаҗ булмыйча, кәсеп рәвешендә хәер сорашып йөрсә, ул үз-үзен фәкыйрьлеккә сала. Динебездә мәчет каршында, мәчет эчендә сәдака соранып йөрү тыелган. Бер хәдистә: «Сәдака сорауны кәсеп иткән кеше сиңа сәлам бирсә, аңа җавап та бирмә», – диелә. Ник дигәндә, ул сиңа сәламне синең белән исәнләшү өчен түгел, үзенә игътибарны җәлеп итеп, үзен мөселман итеп күрсәтеп, синнән акча алу өчен эшли.

:: Соңгы арада авыр хәлдә калган кешегә эшкә урнаштырам, торак табарга ярдәм итәм дип алдап, аны коллыкта тоту, бушка эшләтү очраклары да еш күзәтелә башлады...

– Бу очракта кеше башка кеше гомерен үзләштерә булып чыга. Аны бит кире кайтарып булмый. Ислам дине буенча тыелган күренеш бу. Ул зур гөнаһ санала. Кеше гомеренә беркем дә тияргә тиеш түгел.

:: Без алда телгә алган күренешләр пәйгамбәрләр заманында да булганмы? Әллә ул – заман үзгәргән саен үсә барган бозыклык, әхлаксызлык «җимеш»еме?

– Бу күренешләр элек тә булган. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Алдакчы булу – мөселманга хас сыйфат түгел», – дигән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм базарда сату итүче бер сәүдәгәр янына килгән. Нидәндер шикләнеп, кулын бодай тулы капчыкка тыгып караган да аның өсте генә коры, асты юеш икәнлеген инанган. Ягъни капчыкның авырлыгын арттырып күрсәтү өчен, сәүдәгәр махсус чи бодай саткан. Шуннан пәйгамбәребез үзенең сәхабәләренә: «Кем алдалый, шул бездән булмас», – дип әйтеп калдырган.

ТӘРБИЯ ХАКЫНДА – ХӘДИСЛӘРДӘ

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлләм: «Әти-әни баласына бирә алган иң күркәм әйбер – тәрбия», – дип әйткән. Шулай ук икенче бер хәдистә болай дип әйтелә: «Әти кеше өчен бала тәрбияләү көн саен күп күләмдә сәдака биреп баруга караганда яхшырак». Тагын бер хәдистә: «Тәкъва булыгыз һәм балаларыгыз арасында гаделлек белән эш итегез (аларның һәрберсенә дә бертигез игътибар бирегез һәм кайгырту күрсәтегез)», – дип әйтелә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһи вә сәлләм: «Дөреслектә, кыямәттәге хөкем вакыты үткәч, җәннәттәге бер кеше үзе лаек булмаган дәрәҗәләргә күтәрелер. Ул шулвакыт: «Бу дәрәҗә миңа ни өчен бирелде?» – дип гаҗәпләнер. Аңа: «Бу – балаңның синең гөнаһларыңны ярлыкауны сорап кылган догалары өчен», – дип җавап кайтарылыр», – дип әйткән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«Кеше үлгәч, өч төрле гамәлдән кала кылган гамәлләре өчен әҗер килү туктый. Ул өч гамәл: әҗере бетми торган сәдака – сәдака җәрия, кешеләргә файда китерә торган гыйлем, аның өчен Аллаһы Тәгаләгә дога кылачак изге бала», – дип әйткән.

(«Дин вә мәгыйшәт» газетасыннан)

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хикмәт

Шулай бервакыт бер зирәк карчыктан:

– Әбекәй, син гомер буе авыр тормышта яшәсәң дә, күңелең белән безгә караганда да яшьрәк кала алгансың. Моның берәр сере бармы? – дип сораганнар.

– Бар, балакайларым, – дигән ул. – Гомер буе миңа эшләгән яхшылыкларны – йөрәккә, яманлыкларны суга язып бардым. Киресенчә эшләсәм, йөрәгем хәзер теткәләнеп, яра өстенә ярада булыр иде. Ходай Тәгалә безгә искә төшерү һәм онытту сәләте биргән. Безгә яхшылык эшләсәләр, рәхмәтлелек сыйфатыбыз аны һәрчак истә тотарга өнди, яратуыбыз исә яманлыкны онытттыра.

Йәгез, бер дога!

ЮГАЛГАН ҺӘМ УРЛАНГАН ӘЙБЕРЛӘРНЕ ТАБУ ӨЧЕН

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахиим. Иа җәми'анниси ли-иоумин лә райбә фихи инналлаһә лә юхлиф-ул ми'ад иҗма' бәйни уә бәйнә ...» дип көн дә 25 тапкыр укырга кирәк. Күп нокталар урынына югалган әйберне атап укырга онытмагыз.

ХЕЗМӘТ ХАКЫН АЛГАНДА УКЫЛА ТОРГАН

«Әл-хәмду лилләһи раббил-гааләмиин. Вәс-сәләәту вәс-сәләәму галәә расүүлинәә мүхәммәдин вә әәлиһии әҗмәгыйин. Әллааһүммәрзукъһәә ризкан хәләәлән таййибә. Вәстәҗиб дугаа-әнәә йәә раббәл-гааләмиин. Әллааһүммә иннәә нәгүузү бикә минәл-фәкъри вәд-дәйни, раббәнәә әәтинәә фид-дуньйәә хәсәнәтәүв-вә фил-әәхыйрати хәсәнәтәүв-вә кыйнәә газәәбән-нәәр».

Мәгънәсе: «Аллаһым! Исәнлек эчендә тагын бер ай уздырдык. Шөкерләр булсын. Безләргә пакь һәм хәләл ризыклар бир. Хезмәт хакларыбызны яхшы һәм хәерле җирләргә сарыф итүне насыйп ит. Акчабыз белән безне начар юлларга бастырма. Ибраһим пәйгамбәргә биргән бәрәкәт кебек безгә дә бир, йә Рабби! Дәүләтебезне һәм милләтебезне һәрвакыт яхшы эшләргә юнәлт, догаларыбызны кабул кыл, Аллаһым».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ЗӘРИНӘ АСЫЛКАЕВА:

«ТОТРЫКЛЫЛЫК КЕШЕНЕ ИҖАДИ ЯКТАН ҖИМЕРӘ»

Югары белемле юрист татар эстрадасына ничек килеп эләккән? Ни өчен ул сәнгать мәктәбеннән елап кайтып киткән? «Ни хәл?» сәхифәсенә кунакка яшь җырчы Зәринә АСЫЛКАЕВАны дәштек.

:: Ни хәл?

– Бар да яхшы. Тиздән тамашачымны яңа җырлар белән сөендерәчәкмен, шуңа әзерләнәбез. Шулай ук быел мин тәүге тапкыр Казанда узачак «Татар җыры»нда чыгыш ясыйм. Мондый масштаблы чарада катнашу – минем өчен гаять зур дәрәҗә.

:: Узган ел TMTV премиясендә «Яңа исем» номинациясендә җиңү яуладың. Ул көннән башлап иҗади тормышың үзгәрдеме?

– Бу премия мине тәүге тапкыр зур тамашачы белән очраштырды. Шундый дәрәҗәле вакыйганың бер өлеше булуның тәмен татып карадым. Премиядән соң мине тыңлаучылар ике тапкыр артты, шуңа да мин аларны сөендерү өчен тагын да күбрәк эшли башладым. Дөресен генә әйткәндә, TMTV премиясенә кадәр мин бу хәтле үк булдыра алырмын дип уйламаган да идем. Ул үземә ышаныч тудырды. Хәзер инде тырышсаң, барысын да булдырып була, дип яшим.

:: Ялгышмасам, син урыс телендә дә җырлыйсың, ләкин татар эстрадасы күңеләңә якынрак, ахры.

– Туган телемә һәм татар мәдәниятенә карата мәхәббәт тәрбияләүләре өчен мин әти-әниемә рәхмәтле. Миндә үз республикама карата горурлык хисе яши, татар җырларына мәхәббәт тә йөрәгемдә аерым урын алып тора. Үзем язган тәүге җырым урысча иде. Ул вакытта миңа 12 яшь иде. Шуннан бирле ике телдә дә җырлыйм.

:: Балачагың ничек узды?

– Балачак хатирәләрен барлый башласаң, аларның барысы да шулкадәр җылы һәм якты. Мине һәрвакыт иҗат, мәхәббәт һәм якыннарымның җылысы чолгап алган иде. Әтием, музыкаль белеме булмаса да, искиткеч итеп җырлый һәм төрле музыка уен коралларында уйный. Мин шуңардан күреп кызыкканмындыр инде. Миңа җиде яшьләр тирәсе булганда, кунаклар килгән саен аларга концерт куя идем.

Сәнгать мәктәбендә укый башлавым да бер кызыклы очрак белән бәйле. Бервакыт иптәш кызымның әнисе: «Без хәзер сәнгать мәктәбенә барабыз. Әйдә, син дә безнең белән», – диде. Иярдем. Ни өчендер шул көннән башлап мин дә ул мәктәптә укыймдыр кебек тоелды. Икенче көнне тагын шунда киттем, әлек кергән булмә ишеген ачтым, тик анда берәү дә юк иде. Коридорга чыгып утырдым да, ике сәгать буе берәрсенең килгәнен көттем. Шунда минем янга сәнгать мәктәбе җитәкчесе килде дә: «Нишләп утырасың монда, балам? Син бит безнең мәктәптә укымыйсың», – диде. Кәефемнең ничек кырылганын белсәң! Өйгә йөгереп кайтып киттем дә еладым да еладым. Икенче көнне үк әти-әнием шул мәктәпкә укырга бирде.

Блиц-сораштыру

– Йөрәгең бушмы?
– Әйе.
– Көнең ничек башлана һәм ни белән тәмамлана?
– Көнем елмаюдан, тәмле итеп пешерелгән иртәнге аштан башлана һәм тәмле йокы белән тәмамлана.
– Кумирың бармы?
– Рус эстрадасыннан Jony һәм Елена Темникованың иҗатын яратам.
– Илһам чыганагың?
– Мәхәббәт, мәрхәмәтлелек һәм яраткан шөгыльләрем.

:: Син белемең буенча юрист. Әлеге өлкәдә эшләп караганың булдымы?

Совет офицеры Даян Мурзинны Гитлер үзенең дошманы дип саный, ә фашистлар «кара генерал» дип атый. Бөек Ватан сугышының легендар каһарманы, Чехословакиянең югары орденнары кавалеры, шушы илдәге 16 шәһәрнең мактаулы гражданины – болар барысы да Башкортстанның Бакалы районы Иске Балыклы авылында туып-үскән Даян Мурзин турында. Гитлер шәхсән үзе аңа «ау» игълан итә. Әмма елгыр разведчикны берничек тә кулга төшерә алмыйлар. Чыннан да, кем соң ул Даян Мурзин, Гитлер аның хакында кайдан һәм ничек белә?

Мурзин җитәкчелек иткән бригаданың «кыланмыш»лары дошманны чыгырдан чыгара. Немецлар тарафыннан басып алынган Чехословакияне азат иткәндә генә дә бригада дүрт меңнән артык фашистны юк итә, техника һәм сугыш кораллары төягән 60 дошман поездына һөҗүм ясый. Немецларның танк гаскәрләре генералы Мюллерны әсирлеккә төшерә. Әйтергә кирәк, бу эшләрнең барысы да Гитлерның борын астында эшләнә. Мондый хәлләрдән соң фюрер Даян Мурзинны үзе махсус алып барган «атылырга тиешле» кешеләр исемлегенә кертә. Анда, мәсәлән, Сталин, Рузвельт, Жуков кебек фамилияләр урын ала.

Сугыштан соң Мурзин бик күп нәфис фильмнарның герое була. Тик аларның күбесе Англия, Чехия, Германия кебек чит илләрдә төшерелә. Документаль фильмнарда исә аның хакында фронтовиклар, сугыш геройлары зур горурлык белән сөйли. Аңлашыла ки, сугыш разведчикларының исемнәре, батырлыклары халыкка дистә еллар үткәч кенә әйләнеп кайта. Гадәттә, яшерен булудан туктаган документлар пәйда булгач, инде вакыт үткән, кызыксыну сүрелгән була, шул сәбәпле кылган батырлыклар да тиешенчә искә алынмый. Даян Мурзин да шундый язмышка дучар була.

Куркыныч көннәр

Кем белә, яшьлеге сугыш чорына туры килмәсә, Даян Мурзинның мондый хәрби таланты ачылмаган да булыр иде, бәлки. Ул гап-гади татар авылында туыпүсә, педучилищены тәмамлаганнан соң, туган авылына укытучы булып кайта. Соңрак аны күрше авыл мәктәбенә директор итеп күчерәләр. 1940 елны армия сафларына хезмәт итәргә китә. Менә шунда хәрби эшләргә сәләтен күреп алалар да инде: Ригадагы хәрби училищега юллыйлар. 1941 елның 19 июнендә аны бер төркем иптәшләре белән чик буена күчерәләр, чөнки немецларның һөҗүм итәргә мөмкин икәнлекләре турында хәбәр килеп җитә, әзерлек башлана. Курсантлар окоп казыйлар, канкоеш буласына беркем дә ышанып бетми. Тик сугыш башлана. Даян өчен беренче көннәр бигрәк тә куркыныч була. Ил өстенә бомбалар ташлау өчен бертуктаусыз самолетлар оча, танк өере өстенә килә, янәшәдә генә пулялар сызгыра, иптәшләрең үлем ачысыннан сыкрап ята... Дүртенче көн дигәндә, Даян да яралана, аны иптәшләре сугыш кырыннан алып чыгалар. Әмма хәле авыр булганлыктан, госпитальгә илтеп җиткерә алмыйлар. Дошман кулына эләкмәс өчен, ул иптәшләреннән гомерен өзүләрен үтенә. Әмма бу адымга беркем дә бара алмый, Даянны урман юлы янәшәсендәге канауда калдырып китәргә мәҗбүр булалар. Ике көннән егет аңына килә, ярдәм сорап кычкыра, аны бер латыш крестьяны күреп алып, табиблар янына илтә. Бераз хәл кергәч, Даян үз иптәшләрен куып җитәргә омтыла, тик фронт сызыгы инде бик ерак була.

Әмма бу аңа һич кенә дә фашистларга каршы сугыш алып барырга комачауламый. Ул «Ватан өчен!» дип аталган партизаннар отрядына керә. Батыр һәм курку белмәс икәнлеген күреп, инде беренче операциядән соң ук аны взвод командиры итеп билгелиләр. Озак та үтми, Даян кабат яралана. Госпитальдә дәваланганнан соң аны диверсантлар әзерләүче мәктәпкә укырга җибәрәләр. Мәктәпне тәмамлагач, дошман өненә разведчик булып китә.

Дошман өнендә

Даян Мурзин «Идел-Урал» дип аталган Төркестан легионы составына керә. Анда агент булып, кирәкле мәгълүмат җыя. Разведчикның төп бурычы – яшерен агитация үткәреп, легион составын таркату. Нәтиҗәләр күзгә күренерлек була: Мурзин тырышлыгы белән легионерларның күбесе Кызыл Армия ягына авыша.

Бу хәлләрдән соң Даян Мурзинның сәләтле агент булуында берниндә дә шик калмый. Аны диверсантларның халыкара мәктәбенә күчерәләр. 1944 елның җәендә инде ул дошман басып алган территорияләрдә интернациональ партизаннар отряды белән командалык итә. Ул вакытта аңа бары тик 23 яшь, бригадасындагы бер мең кешенең яртысы аннан ике тапкыр өлкәнрәк була.

Диверсантлар мәктәбендә разведчикка сакал үстерергә киңәш итәләр. Бу өлкәнрәк һәм олпатрак күренү өчен кирәк була. Аның сакалы куе һәм сумала кебек кара булып үсә. Шуннан соң аңа «кара генерал» дигән кушамат тагыла да инде. Ул сакалын ел ярымнан соң, сугыш тәмамлангач кына кырып ата, иптәшләре аның яшь кенә бер малай икәнлеген күреп, бик гаҗәпләнәләр. Әмма бу «малай»га көрәш кырында тиңнәр табылмый. Ул оештырган партизаннар отрядында руслар, инглизләр, итальяннар, французлар, чехлар, словаклар, шул исәптән немецлар да була.

Баш бәласе

Даян Мурзин фашистлар өчен баш бәласенә әйләнә. Чөнки ул җитәкләгән бригаданың кайчан кайда һөҗүм ясаячагын һич кенә дә фаразлый алмыйлар. Шулай бервакыт бригада 18 самолет белән фашист аэродромын кулга төшерә. Дошманның ничек ачуы килмәсен инде! Мурзин бригадасы исәбендә 19 юкка чыгарылган танк, ике йөздән артык автомобиль, 20гә якын тимер юл үтә торган күпер була, 250гә якын фашистны әсирлеккә алалар. Бригада элеккеге совет генералы Андрей Власовны да кулга төшерә. Хыянәтчене сорау алу һәм җәза бирү өчен совет командованиесенә тапшыру Даян Мурзин өчен намус эше була.

Ялган тотыла

Фашистлар Мурзинның «һөнәр»ләре турында шактый белсәләр дә, бу хакта командованиегә җиткерергә ашыкмыйлар. Тик Гитлер бу талантлы диверсант турында ишетә. Эш болай була. Бервакыт шулай фюрер басып алынган территорияләр буйлап сәяхәт итәргә карар кыла. Шул җәһәттән бронепоезд әзерләргә кушыла. Әмма яраннары мондый сәяхәтнең бик куркыныч икәнлеген, исән калуга гарантия бирә алмауларын җиткерергә мәҗбүр булалар. Сәбәбе – поездларга һөҗүм итүче партизаннар бригадасы. Ул вакытта Мурзин майор званиесендә, бригада командиры була. Фюрер яраннары ниндидер бер майорның шундый эшләргә осталыгы турында сөйләргә яхшысынмыйлар. Менә шул вакытта «кара генерал» кушаматы бик ярап куя. Гитлерга Мурзинны грузин, генерал, кара сакал йөртә дип җиткерәләр. Нәтиҗәдә дошман арасында диверсантның абруе бермә-бер үсеп китә. Шушы хәлләрдән соң фюрер Даян Мурзинны «кара» исемлеккә кертә дә инде, аның башы өчен ике миллион марка бүләк вәгъдә ителә. Эзләү эшләре өчен немец диверсанты Отто Скорцени җитәкчелегендә махсус подразделение төзелә. 1944 елның көзендә аны камап алырга телиләр. Мурзин һәм берничә сугышчы Үзәк комитет вәкиле белән очрашуга бара. Бу хакта дошманга мәгълүм була. Фашист автоматчылары юлга аркылы төшеп, исән килеш алу нияте белән, аның аякларына аталар. Мурзин елгага сикерә. Әзәрлекләүдән качып, ярга чыга, урманчы йортына юлыга. Урманчы аны, яраларын эшкәртеп, аю өненә урнаштыра. Урманда немецлар өерләре белән йөриләр. 15 метр ераклыкта гына печән яндыралар, этләр гел өн тирәсендә әйләнә. Әмма хайван исе кешенекенә караганда көчлерәк була, күрәсең. Аю өнендә совет офицеры ята дип, башларына да килми. Соңыннан иптәшләре аны куркынычсыз урынга күчерә. Ә Гитлерга, Мурзин отряды белән юк ителде, дип хәбәр итәләр. Тик ике миллион марка бүләк алучыларның шатлыклары озакка бармый. Мюллер кулга алынгач, ялганнары тотыла. Немец офицерын кулга алырга разведчикка җирле халык ярдәм итә. Бер партизанның туганы бай өендә хезмәтче булып эшли, аларга Мюллер да кергәләп йөри икән. Калганы инде Мурзин өчен техника эше генә була.

Сугыштан соң

Гомумән алганда, Даян Мурзин сугышта күрсәткән батырлыклары өчен 86 медаль һәм орден белән бүләкләнә. Әйтергә кирәк, аларның күбесе СССРныкы түгел. Геройга Алтын Йолдыз да бирелми. Чехиядә Даян Мурзин исемендәге урам бар, аңа бронзадан һәйкәл куелган. Чехословакия Герое дигән исем дә бирелә.

Даян Мурзин 2012 елның 9 февралендә 91 яшендә бакыйлыкка күчә. Туган илендә әллә ни данга күмелмәсә дә, сугышта сәламәтлеге нык какшаса да, ул югалып калмый, тыныч тормышта да үз урынын таба: Башкортстанда эчке эшләр министры урынбасары вазыйфасын алып бара. Радист булып эшләгән хәләл җефете белән сугыш елларында ук танышкан булалар. Туганнары, авылдашлары әйтүенчә, бу гаилә бик матур гомер кичерә. Бабалары сугыш турындагы истәлекләрен сөйләргә ярата, балаларын, оныкларын Ватанны яратырга, булганның кадерен белеп яшәргә өнди.

P.S. Быел 2 декабрьдә Даян Мурзин белем алган Кушнаренко көллияте территориясендә Герой истәлегенә бюст куелды.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сәрвәр Нәфыйкова

«МИН КИТӘМИМ...»

ӨЧ ЯШЬЛЕК БАЛАНЫҢ ЯЗМЫШЫН ҮЗГӘРТЕРГӘ ШУШЫ СҮЗЛӘР ҖИТЕП АША

...Өстәлдәге бөтен тәмлүшкәләрне туйганчы ашап, мунча да керен чыккач, йөзе алсуланып, күзләренә нур кергән кыз мич башына менеп утыра һәм: «Мин китәмим, мин китәмим», – дип такмаклап елый башлый. Аны кабат ферма өенә илтеп куярга дип киенә башлаган өлкәннәр аптырап кала.

Өлкәннәр дигәне дә бит аның – үзләре гаилә корырга өлгермәгән ике кыз. Берсе – фермада, икенчесе тракторда эшләүче Сәрвәр белән Зифа. Берсе – Нормада, икенчесе Көшкәтбашта туып-үскән, икесе дә Соснага колхозга эшкә килгән, икесе бер фатирга төшкән. Шулай бергә яшәп калганнар... Бу өч яшьләрдәге кызга бер катнашлары да юк. Үз әнисе ерак туганнарына калдырып, Мари Иленә киявгә чыкканнан соң бөтен тормышы ферма өендә үткән, сыер савучылар кызганып биргән сөт белән җан асраган кызны кунакка дип кенә алып кайтканнар иде бит. Аш үткәргән көнне, әйдә, бу ятим сабыйны да сөендерик диюләре иде. Күз яшьләре белән ярсып елаган баланы ничек кире илтмәк кирәк... Шулай итеп, кыз бирердә яшәп кала...

– Ай буе мунча ягып, мине беттән чистарткан алар, – дип искә ала ул көннәрне бүген инде үзе дүрт онык әбисе булган Гөлнур апа Борһанова. – Бер-берсебезгә бик тиз ияләштек. Икесе дә тырышып эшләгәч, алар бик җитеш тормышта яшәделәр. Мин дә инде монда мохтаҗлык-ачлык күрмәдем, кеше кимәгән киемнәрне генә кидертте алар миңа. Авылда ул чакта пәлтә ике генә кызда – шуның берсе миндә иде. Мин аларга апай дип үстем. Алай да бер чакны, тау шуганда егылып, бик каты борынымны канаттым. Шул чакта Зифа апа суга бара иде. Аны күреп: «Нәнә!» – дип кычкырып, елап, янына йөгердем. Менә шул көннән Зифа апа нәнәгә әйләнде. Сәрвәр апа үпкәләмәде. Үз әниемә килгәндә, ул төрмәдән кайткан булган. Әтинең кем икәнен белмим. Документта Мөбарәк кызы булып йөрим. Кем ул, кайдан, төрмәдә туганмынмы, кайткачмы, анысын да әйтүче булмады... Хәер, үзем дә кызыксынмадым, кирәксенмәдем, димме...

Гөлнур мәктәптә укый башлагач, үз әнисе аны эзләп, авылга берничә тапкыр кайта. Тик Зифа белән Сәрвәр инде бу кызга шулкадәр ияләшкән була, аны югалтудан куркып, көрештермиләр. Алай гына да түгел, урлап китмәгә дип шикләнеп, кызны чиратлашып саклап йөртәләр. Мәктәптән дә каршы барып алалар, уенга чыкса да, күз уңыннан югалтмаска тырышалар... «Әни миңа кешеләр артыннан открыткалар, 8 Март белән котлап, яулыклар да җибәрде. Әмма мин аларны беркемгә күрсәтмәдем, ертып ата идем. Шулай да, үскәч, әнине эзләп табарга, күрергә иде дигән теләк бар иде күңелдә. Әмма насыйп булмады. 24 яшемдә шушы авыл егете Госманга кияүгә чыгып, өч бала үстердек. Башта тормыш мәшәкатьләре мөмкинлек бирмәде, аннан бер-бер артлы катлаулы биш операция кичердем, ул елларда аны эзләү кайгысы булмады», – ди Гөлнур апа.

Зифа әнисе дә, Сәрвәр апасы да балалары өчен кадерле әби була, берсе – 95, икенчесе 86 яшендә, кадер-хөрмәт күреп, ахирәткә күчә... Тудырган әнисе алардан күпкә алда үлә. «Мин аны гафу иттем дип уйлыйм, өчесен дә догадан калдырмыйм...» – ди әңгәмәдәшем.

Әлеге изге күңелле кызларның берсе – Сәрвәр Нәфыйкова районда, республикада тимерче кыз буларак билгеле кеше, 1967 елда Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган, Ленин ордены белән бүләкләнгән. Заманында аның турында язмаган газета-журнал калмый. Үзем дә күп еллар элек, ул чакта әле бернидән зарланмый, бер минут тик утыра белми торган таза-нык әби чагында аның турында язган идем. Яшьлеге, эше турында, ул чор геройлыклары турында озаклап сөйләштек. Әмма язмышның бу «борылма»лары турында ул берни дә әйтмәгән иде.

Гөлнур ападан кабат әлеге кыю кызлар турында сорашам.

– Сәрвәр апа тракторчылар курсында укып, башта тракторчы булып эшләде. Аннан тагын махсус курслар бетереп, эретеп ябыштыручы, ә бераздан тимерче булып күчте. Нинди эшкә тотынса, шуны булдыра торган, бик тырыш, батыр йөрәкле кеше иде ул. Әле берничә елдан тагын тракторга утырып, пенсиягә чыкканчы эшләде. Ә Зифа апа гомере буе фермада булды. Ул тегәргә-чигәргә бик оста иде, кадак кагу, печән чабу, утын яру кебек ир-ат эшләрен дә бик булдырып эшләде. Сәрвәр апа өстендә йорттагы барлык мал-туар булды. Алар бөтен төрле малны да асрап, бик тырыш хезмәт белән көн күрделәр. Үндүрт баш умартага кадәр асрадылар. Эштән арымадылар да, авырсынмадылар да, – дип искә ала Гөлнур апа. – Сәрвәр апаның Герой исемен алуын бик әйбәт хәтерлим. Ул чакта мәктәптә укый идем. Безнең турыда ул чакта бөтен җирдә яздылар. Хәтерлим әле, язучы Кояш Тимбикова да килгән иде. Миннән: «Ничек яшисең?» – дип сорагач, «Төрле вакыт була», – дип җавап биргәнем истә. Ул Сәрвәр апа турында «Тимерче кыз» дигән повесть язды. Мин бу ике олы йөрәкле апа-кызларга бик рәхмәтле, алар булмаса, мине нинди язмыш көткән булыр иде икән... Мине, үлеп беткән кызны, аякка бастырган, икенче тормыш – рәхәт тормыш бүләк иткән кешеләр бит алар...

...Бүген Соснада бер урам Герой Сәрвәр исемен йөртә, аның бюсты район үзәгендәге Батырлар аллеясында урын алган. Баксаң, тимерче кызда олы йөрәк – алтын йөрәк булган икән бит... Икеләтә герой...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

АҢЛАШЫРГА СҮЗ КИРӘКМИ

Питрәч районының Чыты авылында гомер итүче Хәмит абый Шәмсетдиновның колагы да ишетми, сөйләшә дә алмый. Әмма үзен бер дә авыруга санамый ул. Язмышына риза булып яши. Әле ул гынамы, тиздән 70 яшен тутыруга карамастан, Хәмит абый хәзер дә эшләп йөри. Гомере буе тимерче булган. Аны алыштырыр кеше таба алмыйлар икән. Бу эшкә яшьләрнең исе китми, ә хуҗалыкта тимерчесез булмый.

– Безнең әти 15 яшендә эшли башлаган. Башта тимерче ярдәмчесе булган, аннан бу эшне үзенә генә ышанып тапшырганнар. Башкалар төсле сөйләшә алса, ишетсә иде дә бит әле! Хезмәт ярату аны көчле иткән. Авыру хакында уйлап утырырга вакыты булмаган. 7 туган үсә алар. Әти-әнисенә тормыш алып барырга ярәм итәргә дип, әти эшкә тотынган, – дип сөйли улы Миннур.

Кечкенә чагында Хәмит абыйның колагы да ишеткән, теле дә ачылган. Әмма бер вакыйга аны гомерлеккә гарип калдыра.

– Аңа ике яшь булганда, өстенә шкаф ава. Авыз-борыныннан кан китә. Әбине эштән чакырып кайтаралар. Ул кайткач, бала тынычлана, – дип сөйли Миннур. – Башта бабайга сиздермиләр. Тик берничә көннән ул кечкенә улының ишетмәгәнен аңлап ала. Табиблар янына алып барганда соң була инде.

Гаилә ишарәләр белән аңлашырга өйрәнә. Әти-әнисе исә улларының ни әйтергә теләгәнен күзеннән үк аңлый. Хәмит тә югалып калмый. Дуслары да күп була, аеруча күрше егетен якын итә. Гел бергә булгач, бик җиңел аңлашалар. Менә шул дусты аны кызлар янына ияртеп йөртә башлый. Бервакыт күрше авылга баралар. Хәмитнең күзе Мәсәния исемле кызга төшә. Әлбәттә инде, серен дустына ача. Сөйләшмәгән, танышмаган, бер озатмаган килеш кызны яратып буламыни? Хәмит исә тимерне кызуында суга. Өйләнергә җыенганын әти-әнисенә әйтә дә икенче көнне үк кызны урлап та кайта.

– Әнинең исә бер дә монда каласы килми. Сөйләшмәгән кеше белән ничек яшәрмен, җитмәсә, ишетми дә, дип өзгәләнә ул. Киленне иртәгәсен кире илтергә килешәләр. Ә ул вакытта аның әтиәнисе, кызларын эзләп, юлга чыккан була инде. Алар килгәч, аңлашалар: килен егет янында кала, – дип сөйли Миннур.

Мәсәния апа гомере буе иренә рәхмәтле булып яши. Кызганыч, алты баладан бүген икесе генә исән-сау. Калганнары кечкенә вакытта вафат була. Әнә шул хәсрәтләр ир белән хатынны тагын да якынайта, бер-берсенә терәк булырга өйрәтә.

– Мин Хәмитемә рәхмәтле. Хәзер уйлыйм – башка ирләр кебек ямьсез сүз түгел, кыек караш та ташламады. Миңа терәк булды. Авырыйм дип тормады – кулыннан килмәгән эше юк. Авылда Хәмитемнең хезмәте кермәгән бер генә йорт та юктыр, – ди ул.

Улы Миннур исә әнисенә дә сокланып яшәрми.

– Бигрәк сабыр булган инде. Иреннән бер ярату, назлы сүзләр ишетмичә дә яши бит. Аның да башка хатыннар кебек ул сүзләрне ишетәсе килгәндер, – ди ул.

Хәмит абыйны эшендә бик хөрмәт итәләр. Ярдәм кирәк булгач, күрше хуҗалыклар да чакырып ала. Әле былтыр рәхмәт йөзеннән бер машина ашлык китереп биргәннәр.

– Әти бөтен тимер эшен белә. Ишек, капка, аркалар ясый. Бергәләп чишмәләр дә төзәтәбез. Ул – бик сабыр кеше. Кайдандыр китереп биргәнне көтеп утырмый. Үзе эшләп таба. Авыру буенча тиешле инвалидлык артыннан да йөрмәде ул. Пенсиягә чыгар вакыты җиткәч, без аның ялга иртәрәк тә китә аласын белдек. Анысында да кәч-хәл белән ризалашты. Бөтенесен үзе эзләп табарга өйрәнгән кеше ул, – ди улы.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ҖЫРНЫҢ ЕРТЫГЫ БУЛАМЫ?

Соңгы арада татар эстрадасы җыр белән түгел, төрледән-төрле низаглар белән шаккатыра. Гадәттә ул низаглар халык арасында бик үк популяр булмаган җырчыларга бәйле була. Шулардан чыгып уйга каласың: җыр белән популяр булмагач, шау-шу белән халык теленә керү ысулы түгелме икән бу? Популяр җырны башкарып кына танылып буламы? Татар эстрадасы дөрес юлдамы, үсештәме? Болар хакында Татарстанның халык артисты, композитор, Россия авторлар җәмгыятенең Татарстандагы бүлеге җитәкчесе Зөфәр ХӘЙРЕТДИНОВ белән сөйләштек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Зөфәр абый, соңгы вакытта җыр бүлешүгә бәйле низаглар еш чыгып тора. Мондый очракларда кем хаклы булып кала?

– Низаг җырчыларның хокуклар өлкәсендә грамотасыз булганлыгы аркасында килеп чыга. Сәнгатьтә эшлисең һәм шушы өлкәдә гомереңнең шактый өлеше узган икән, син үзеңнең, җырның, автор хокукларын белергә тиеш. Һич югы шуларның нигезләрен белергә кирәк. Дилә Нигъмәтуллинага бәйле сораудир инде бу. Ул низагны беренче чиратта пиар, икенчедән, болганчык суда балык тотарга маташу дип бәяләргә мөмкин.

:: Димәк, җыр ул – милек?

– Җыр – аны дөньяга тудырган кешеләрнең милке. Милек хокуклары ике төрле була. Милки хокук һәм милки булмаган хокук. Милки хокук бозылган очракта штрафлар һәм җәзалар каралган, ә милки булмаган хокукка каралмаган. Әйтик, синең җырны кемдер кайдадыр авторын әйтмичә генә башкарды ди, аңа бернинди җәза каралмаган. Чөнки автор бу очракта милки зыян күрми. Дилә Нигъмәтуллина белән килеп чыккан очракны алсак, анда вазгыять икенче. Дөрес, Дилә миннән «Миләшләрем» җырын башкару өчен күптән рөхсәт сорады. Сорамаса да, ул җырны җырларга мөмкин иде. Әгәр җырга тыю салынмаган булса, һәр җырны башкарырга була. Ретро җырларны бигрәк тә. Билгеле, ул җырлар белән автор идарә итми, рөхсәт РАО аркылы алына. Килешү нигезендә син җырлыйсың һәм авторга концертыңнан гонорар түлисең. Диләгә мин шулай аңлаттым да. Билгеле бер вакытка кадәр ул шулай барды. Ләкин бит автор җырны үзенә файда китерсен дип яза. Бервакыт Лэйна лейблы командасы шушы җырны сорап мөрәҗәгать иткәч, әлеге җырга биш елга хокукны шушы лейблга тапшырдым. Команда төпле, юридик яктан да шактый көчле. Шунысын да искәртим: моңарчы җырның хокукларын билгеле бер җырчыга тапшырганым булмады диярлек. Әмма мин аларны, бу җыр популяр һәм аны бик күпләр җырлый, дип кисәттем. Алар, җырласыннар, әмма рәсми төстә, ягъни зур сәхнәләрдә җырлаучылар булмасын, диде. Күпмедер вакыт узгач, Дилә алар төшергән клипны күргән һәм миңа шалтыратып сорады. Мин хокукларны сатканымны хәбәр иттем. Хәзер Дилә аны рәсми булмаган шартларда, туган көннәрдә, туйларда, ягъни тар даирәләрдә генә җырлый ала.

Мин шулай ук аңа үземнең юбилей кичәмдә зур залда әлеге җырны башкара алачагын хәбәр иттем. Лейбл егетләреннән бу концертта башкару өчен рөхсәтне үзем сорап алдым. Алар рөхсәт бирде. Күрәсезме, барысы да рөхсәт алуга кайтып кала.

Дилә исә бу сөйләшүне үзенчә аңлаган, шыпырт кына җырлаштыргалаган. Моны күргәннәр, кисәткәннәр. Дилә исә янә тырма башына баскан, Барс-медиа дискотекасында җырлап, ул телевидениедә күрсәтелгән. Шушы материал нигезендә аны судка биргәннәр. Бу әле – бер очрак кына. Андый очрак тагын да булган. Кызганыч, җырчы эшне үз агымына куйган һәм суд карары чыккач кына «Инстаграм»да хәбәр салган. Шунысы да бар: бу җырны Дилә түгел, Алсу Хисамиева визит карточкасына әйләндерде. Дилә аннан файдаланды гына, автор буларак миңа аннан бернинди файда килмәде.

:: Мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле: Алсу Хисамиева әлеге җырны кайдадыр башкарырга уйласа, Лэйна командасы аны да судка бирәчәкме?

– Әлбәттә, юк. Килешүдә автор үзе һәм аны беренче башкаручы җырларга хокуклы дип язылган. Аларның бу җырга әхлакый хаклары бар. Аны бернинди килешү дә юкка чыгара алмый.

:: Шунысы кызык: яшь җырчылар туксанынчы еллардагы җырларга кызыга, шулар ярдәмендә популярлык казанырга тырыша. Моның сәбәбе нәрсәдә? Заманча яхшы җырларга кытлыктамы?

– Дөрес. Чөнки 80–90 нчы елларда эстрада өлкәсендә базар мөнәсәбәтләре генә түгел, нәфис сәнгать мөнәсәбәтләре бар иде. Худсовет җырларны инәсеннән җебенә кадәр тикшерде. Анда көй дә, сүз тәңгәллеге дә, җырчының башкару осталыгы – бар да исәпкә алына иде. Шундый очраклар да булды: җыр инде халык арасында популярлашып беткән була, ә худсовет кабул итми. Моның сәбәбе төрле.

> Җырның ертыгы юк, диләр, ертыгы бик күп аның. Бүген кулланышта ертык җырлар йөри. Җырлый башлаучылар шуңа да ретрога ымсына. Ник дигәндә, концертка йөрүчеләрнең 50 процентын урта һәм өлкән яшьтәге кешеләр тәшкил итә. Утыз яшьләрдәгеләр – тамашачының 5–10 проценты гына. Шуңа күрә җырчы урта һәм өлкән яшьтәгеләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерергә тырыша. Болар инде – ретро җырларны сагынучылар. Акыллы җырчылар моны аңлый.

Ул җырлар арасында азрак талпынып, алга китеп алган, әмма тулы куәтенә ачыла алмаганнары да шактый. Шуларны алып, заманча аранжировкалар белән халыкка җиткерү җырчы өчен дә, җыр өчен дә файдалы. Элвин Грейның «Уфтанма» җыры нәкъ менә шундый. Салават репертуарында ул гадәти җырларның берсе иде. «Салкын чәй», «Мин яратам сине, Татарстан» шикелле Салаватның үз җыры булып китә алмады. Ә менә Элвин Грейның визит карточкасына әйләнде.

> Без еш кына гади ялтыравыктыр бу дип, җирдә яткан ташны алмый китәбез. Кемдер ала, шомарта, алмаз дәрәҗәсенә җиткерә. «Миләшләрем»ә кайтсак, аны Дилә Нигъмәтуллина да, Лэйна да халык күңеленә яңа формада, тагын да яхшырак итеп җиткерделәр, дип әйтеп булмый. Тырыштылар, әмма җыр Алсу Хисамиеваныкы булып калды.

:: Җырчыларның хокукларны сатып алып, тыюлар аша эш итүе башкаларны мине уздырырлар дип куркуданмы?

– Анысы да бар. Икенче бер җырчы башкарганнан соң, тагын да популяр булып киткән җырлар бар һәм алар бик күп. Бер җырны унга якын җырчы җырлаган мисаллар да бар. Мисалга Зәйнәб Фәрхетдинова башкарган «Талларым» җырын алыйк. Аны кем генә җырламады. Барыбер Зәйнәб варианты эталон булып калды. Күпме генә кеше башкарса да, җыр бер генә җырчының эталоны булып кала. «Су буенда учак яна» җыры исә – кем генә башкарса да, Зөһрә Шәрифуллинаныкы. Бар шундый җырлар: ул җырчының йөзенә әверелә.

Бездә бүген җырлар да, җырчылар да шулкадәр күп, җырларны гына түгел, җырчыларын да хәтерләп бетерә торган түгел. «Мәйдан» каналын ачам икән, җырчыларның туксан процентын белмим, күргәнем дә юк. Күрергә туры килмәс тә, бәлкем. Алар елга буена килеп кармак салучыларны хәтерләтә. Кабармы икән балык (тамашачы), юкмы? Капса, тагын бераз җырлый инде ул. Хәзер бит теләге булган теләсә кемнән җырчы ясап була. Мөмкинлекләр зур. Әмма эстрада үсми, чүпләнә генә. Элек худсоветларның файдасы зур булгандыр. Нинди генә тавышлы булмасын, җырчыда харизма булмаса, аны филармониягә дә, башка оешмаларга да алмыйлар иде. Җырчы бит җырларга гына түгел, халыкка күңел байлыгын, интеллектын җыр аркылы җиткерергә тиеш. Тавыш шәп, әмма җырлаганда күңеленең дә, башының да буш булуы сизелеп тора. Андыйлар, кызганыч, күп.

:: Сезгә туксанынчы елларда язылган җырларны сорап килеләр. Бәлки яңа җырчыларга яңа җырлар язып бирергә кирәктер?

– Иҗатым туксанынчы елга кадәр һәм аннан соңгы чорга бүленә. Туксанынчы елга кадәр нәрсә телим – шуны яздым. Бүген ничек язылды икән болар дип үзем дә шаккатам. Моннан да популяр җырларны язып булмастыр дип тә уйландыра. Бүген нәрсә телим, шуны язам дип әйтә алмыйм, чөнки дөньяга карашым үзгәрде. Тәрбияви җырлар язасым килә. Элек тә мәгънәсез җырлар тумады, хәзер исә текстка талымлылык тагын да артты. Җырда ниндидер яңалык булмаса, аңа алынмыйм да. Попса минем өчен – аркылыга-буйга йөзгән диңгез инде ул. Шуңа халык җырларына якын җырлар язасым килә. Ул мәгънәсе белән генә түгел, дәрәҗәсе белән дә аерылып тора.

:: Андый җырларны җырлаучылар бармы соң?

– Бик сирәк. Мин акыллы җырчылар һәм акылсыз җырчылар була дип саныйм. Акылсызы композиторга, миңа «быстрый» җыр кирәк, дип килә. Җыр «быстрый» да, «медленный» да була алмый. Ул яки яхшы, яки начар була. «Быстрый»ны теләүчеләр – югарыга тизрәк үрмәләргә тырышучылар инде алар.

:: Тагын сольный концертыгыз буламы?

– Кирәк түгелдер, мөгаен. Мин башкарырга теләгәннәрнең күбесе – лирик җырлар. Халыкның андый җырларны тыңларга исәбе юктыр, мөгаен. Ә минем башка җырларны җырлыйсы килми. Миңа ошаган бер җырчы бар. Ул – Зөлфәт Хәким. Синең нәрсә тыңлыйсың килә, дип уйламый Зөлфәт. Мин нәрсә җырлыйм – син шуны тыңлыйсың, дип эш итә. Аның җырлары поп-рок стилендә язылган, фәлсәфи. Аларның үз тамашачысы бар. Ә кайберәүләр аңламый да, тыңламый да аны, чөнки аларга «быстрый» җырлар кирәк.

Блиц-сораштыру

– Иң зур теләк?
– Мин башлаган эшләр, гаиләм беркайчан да йөземә кызыллык китермәсен иде. Алар белән горурланып яшәргә язсын.
– Тормышта таянычыгыз?
– Хатыным, гаиләм.
– Тормышта үкенечләр бармы?
– Үкенечсез тормыш була алмый. Үкенеч ул сабак алу өчен кирәк.
– Күңелегезгә килгән җыр?
– Кол Шәриф турында җыр яздым. Шуның белән хыялланып яшим. Иң зур теләгем – шушы җырга клип төшерү. Һәрбер җырга клип ясауның кирәге юк. Ә бу җырда булачак клипның сюжеты ята.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Тулы варианты – сайтта >

Әсәрнең дәвамын 2022 елның гыйнварыннан укый аласыз >

РАВИЛӘ ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ

ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН

(БӘЯН)

Авылга Зәйтүнә кайтып төште. Яңа гына борын асларына кара төкләр чыга башлаган, тавышларына ирләр төсмере кергән яшь-җилкенчәк малайлар арасыннан гармунчы Әгъләм:

– Карагыз әле, Урал якларыннан Фатыйма түтиләргә кунак кызы кайткан, – диде. – Шундый матур, ди. Татарча да белә икән. Ну бүген үзем эләктерәм кунак кызны. Әле миңа бер генә кызның да карышканы юк. Чөнки бер генә аулак өйнең дә Әгъләмнән башка узганы юк. Һы-һы, гармунчысыз аулак өй буламыни! Ягез, бичер үткәреп карагыз миннән башка! – дип, черт итеп ирләрчә төкереп куйды ул.

Ялантау буенда көтү көткән малайлар дәшмәделәр. Әгъләмнең борын югары. Каршы төшсәң, колун балта хәтле йодрыгы белән яңак төбеңә менеп төшәргә дә күп сорамас. Ул әле малайлардан биш яшькә олырак та.

– Кыз кемгә карар бит әле. Шайтаныма кирәкме аңа синең татарча гармун уйнавың? Ул Свердлауда, урыслар арасында үскән. Әле татарчасы да ипилек-тозлык кынадыр, – диде Хыялый Сәет.

Малайлар арасында шау-шу купты. Алар таралып киткән маллары турында да оныттылар. Сыерлар акрын гына уҗымга кереп бара иде.

Бер аягында чәкәнли-чәкәнли, Сәетне үчекли торган иде: «Сәет – хыялый, уй-фикерен җыялмый». Соңгы вакытта бу кыз да үзгәрде. Сәет янынннан озын керфекләрен түбән төшереп, шым гына үтеп китә башлады. «Кара, Хәниянең керфек очларын кояш ашаган», – дип уйлап куйган иде Сәет, иртән көтү куа төшкән кызга текәлеп карап. Кызның инде торнаныкы шикелле озын аяклары тулыланып, билләре нәзекләнеп, тактa кебек түшләре матур гына түгәрәкләнеп килә.

Тик бүген Сәет Хәния турында уйламый. Аңа әллә нәрсә булды. Әле үзе белмәгән, күрмәгән кунак кызы Зәйтүнәне күрәсе килү аның бөтен вөҗүден биләп алган иде.

Тамагына ашау үтмәде. Сәет кәгазь бөкесен тешләре белән суырып алды да шешәдән генә голт-голт итеп сап-салкын сөт эчте. Аннары чикләвек куагы төбенә барып ятты. Күзләрен зәп-зәңгәр күктә йөзгән болытларга төбәде. Болытның берсе Ялантау өстеннән йөзеп барган көймә шикелле иде. Мәктәпне бетергәч, армиягә флотка китәм, дип хыялланып алды ул. Моряк киемен киеп кайтып, Хәниянең һушын алам әле... Аннан үз уйларыннан оялып, югалып калды. Әнә колаклары да кызара башлаганын тойды бугай.

Әгъләм:

– Чукындыра хәзер персидәтел, – дип, маллар артыннан чапты.

Озын Исмәгыйль:

– Сыерлар күбенсә, персидәтелгә хәтле эти иманыңны укыта әле синең, – дип кычкырды.

Малайлар барысы да басуга таба йөгерделәр.

Малларны, су эчертеп, көндезге туплауга җыйганда, инде эсселеккә түзәр әмәл калмаган иде. Малкайлар Ялантау буенда ышык җирдә бергә тупландылар. Малай-егетләр исә, Ялантау итәгендәге зур ташка утырып, әниләре биреп җибәргән төенчекләрен чиштеләр, тамак ялгап алырга җыендылар.

Шешәдәге сөтләрен килә-килешкә чишмә суына тыгып калдырганнар иде. Төенчекләрендәге күкәй, инде майлары сеңеп беткән кара ипи телемнәре, дарудан бушаган кечкенә банкаларга тутырылган повидло, берике баш суган, кабыклы бәрәңге, шырпы тартмасына салынган эре тоз – барысы да таш өстәлгә тезелде. Табын уртак иде.

Сыерлар, мыш-мыш килеп, койрыклары белән шапшоп кигәвен куалар. Сирәк-мирәк кенә ямансулап мөгрәп алалар. Күктә тургай сайрый. Айба тавы буенда ап-ак казлар яңа гына кауры чыгара башлаган бәбкәләрен тилгәннән саклый. Төрле чәчәкләр белән чуарланган яшел тугайда бал эзләп йөргән эшчән умарта кортлары бызылдый. Дүртәр канатлы энә караклары болынны иңләп әйләнәләр. Әнә чуар канат күбәләк, чәчәк дип белеп, шайтан таягына килеп кунды.

– Егетләр, карагыз әле, теге күбәләкнең йөрәгенә энә кадалды, ахры, бик тиз очып китте, – диде нечкә күңелле Хыялый Сәет. Сәеткә «Хыялый» кушаматын авыл малайлары такты. Сәет сүгенү сүзләре кушып сөйли торган авыл малайларынан кай ягы беләндер аерылып тора иде. Ул: «Таллыкта былбыл ничек өзгәләнә, аны сөйгән яры ташладымы икән әллә? Карагыз әле, малайлар, елый түгелме соң ул?» – дип шаккатыра. Мондый хисләрне аңлый алмаган малайлар чигәләренә бармакларын куеп күрсәтәләр – җүләр бу, янәсе.

«Җүләр» сүзе малайга ябыша алмады. Ә менә «Хыялый» дигәне Сәеткә чәп итеп ябышты.

Болын гөж килә – төрле күбәләкләр оча, кошлар сайрый, чәчәкләр хуш исле таҗларын кояшка таба ачалар. Әле бер тапкыр да үбешү тәмен татымаган кызлар ирене кебек кызыллары, кызлар күзләредәй зәңгәрләре, шәмәхәләре бар. Сәет чәчәкләрне кызларга охшата. Аңа бүген әллә нәрсә булган иде. Әллә нинди таныш түгел тойгы бимазалый аны. Күз алдына күрше кызы Хәния килеп басты. Бу кыз кечкенәдән,

Малайлар тамакларын туйдырдылар да әтиләреннән урлап алып килгән тәмәкеләрен кабыздылар. Чәчәк, бал, мәтрүшкә исеннән оеган тугайга сасы тәмәке исе таралды.

– Сәет, Сәет, мә, син дә суырып кара, шундый шәп, башларың әйләндерә, – дип кыстады инде ачы балны да татып караган Әгъләм.

Сәет дәшмәде.

– Әйтмәсәнә шул Хыялыйга, – диделәр корык-корык ютәлләгән малайлар.

Боларның тизрәк егет буласылары, тизрәк балалыктан чыгасылары килә иде. Авыл ягыннан чиләкләр чылтыраган, кызлар көлгән авазлар ишетелде. Бер төркем кыз-кыркын суга төшеп килә. Әһә, диделәр малайлар, хәзер без боларны салкын чишмә суы белән коендырабыз. Чыркылдашып алсыннар әле. Сәет уртада көлә-көлә нидер сөйләп килүче Хәнияне күлмәгеннән танып алды. «Бүген көтү куарга да шушы күлмәген кигән иде», – дип уйлап куйды ул. Чәчен ике толым итеп үргән. Атлаган саен, толымнары тибрәлеп-тибрәлеп китә. Сәетнең йөрәгә кысылып куйды. Соң шул ук чикерткә кебек Хәния бит инде ул. Нәрсә булды соң бу дөньяга бүген? Аптырады Сәет. Әнә Нәҗия, Нурҗиһан, Ләбибә, Сания, ә теге кара бәдрә чәчләрен тузгыткан, ыска итәк кигәне ят кыз. Тукта әле, кунак кызы шул микән әллә?

Сәет яткан җиреннән торып утырды. Күлмәк изүләрен рәтләде. Бармаклары белән чәчләрен тарады. Шунда, никтер, үзенең кыяфәтен көзгедә күрәсе килде. Йөгерә-йөгерә чишмә буена килде дә тиз генә, малайлар күргәнче дип, чишмәгә иелде.

Чишмә суы улактан агып төшкән урында дулкынланып тора да, ага торгач, тынычланып, нәкъ көзге кебек була. Сәет чишмә көзгесенә карады. Су өстеннән аңа кап-кара дулкын чәчле, зур күрән күзле чандыр гына егет карап тора иде. Сәет, битенә ут капканын тоеп, тиз генә кушучына су алып, йөзенә сипте. Чишмә-көзгедә Сәетнең йөзе әллә ничәгә бүленде. Каш-керфекләрендә эленеп калган су тамчылары әллә нинди төсләргә кереп җемелдәделәр.

Ул арада кыз-кыркын чишмәгә килеп җитте. Хәния Сәеткә бер генә күз сирпеп алды да керфекләрен түбән төшерде. Ник мин аның шундый матур икәнен бүген генә күрдем соң? Югыйсә көн саен мәктәпкә бергә йөрделәр. Укудан кайтуга, ничә еллар инде Сәетнең бабасына чишмә суы кертә Хәния. Әнисе дә: «Бар, Зариф бабаңнарның идән-сәкеләрен юып чык», – дип кертеп җибәрә иде кызын. Соңгы араларда Хәния аларга керми башлады.

Дәвамы бар >

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Язып кына карыйм

БАШСЫЗ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

< Дәвамы. Башы 26 ноябрь санында

Яшәү теләге

Үз башыңа төшкәнче, бернәрсәгә дә артык игътибар биреп бетермисең икән. Хәтта ачык мәгълүматны да үз калканчаңнан кабул итәсең. Бездә менә болайрак бит ул... Интернетка керәсең, шундыйрак хәбәр каршы ала: бүген фәлән-фәлән ковид очрагы теркәлгән, яки бүген ковидтан фәләнчә кеше вафат булган. Социаль челтәрләрне карыйсың: кемнеңдер кеме шушы яман авырудан үлгән.

Гел шундый нәрсә белән очрашып торгач, кеше күнелендә: «Бу – бик начар авыру, аннан барысы да үлә, берәү дә исән котыла алмый», – дигәнрәк тәэсир кала икән. Мин моны хатынны хастаханәгә салганда ук аңладым. Хушлашкан вакытта без кабат очраша алмабыздыр кебек тоелды. Күңел тулды. Һәм мин дөньяның барлык көчләренә ялварып, аның терелеп чыгуын теләдем.

Үземне яткыргач та шундыйрак өметсезлек басты. Төнлә китерделәр, берүзем бер бүлмәдә. Хатын авыр хәлдә. Балалар өчен дә борчылдыра. Бик якын җибәрмәскә тырышсак та, аларга да йокмады микән, дип уйлыйсың. Йөгереп барып кына тикшеренерлек урыны да юк. Һәм иң нык үзәккә үткәне – «бу авырудан исән калып булмый» дигән фикернең аңыңа үтеп кергән булуы. Акылың белән алай түгеллеген аңласаң да, күңел үзенекен даулап чәбәләнә.

Мәгълүмат чараларында уңышлы очракларны күбрәк яктыртырга кирәк икән. Өмет өләшерлек язмаларны күбрәк чыгарырга. Ковид нинди генә авыр чир булмасын, терелеп чыгучылар барыбер күп. Бу өлкәдә җитди эшләр алып барыла. Табиблар, гомумән, медицина хезмәткәрләренең эшчәнлеге батырлыкка тиң. Кешелекнең иң төп коткаручылары бүген – алар.

Табиблар... Бу өлкәдә эшләгән табибларга хәйран калырлык. Алар һәр авыруны туганнары кебек күреп, сүзләре белән дә, эш-гамәлләре белән дә дәвалый. Исемләп тә әйтә алмам, кайберләрен йөзгә дә танып белмәм. Гел битлектән, яшел киемнән булгач, йөзләрен истә калдырып булмый. Ләкин мин аларга һәрвакыт рәхмәтле. Бер караганда, адәм балаларын дәваларга күктән төшкән чит планета кешеләре шикелле тоела алар. Яшел кешеләр... Икенче караганда, Җирне коткаручы фәрештәләр кебек.

Авыр хәлдәге кешегә кан бирәләр бит әле... Болар үзләренең канын түгел, ә җаннарының бер өлешен биреп, авыруларны якты дөньяга кайтаралардыр кебек тоела. Бәлки, чынлап та шулайдыр ул. Бәлки, без, әлеге авыруга юлыккан кешеләр, фәкать шушы кешеләрнең фидакарьлеге нәтиҗәсендә генә исәнбездер, безнең җаннарыбызда аларның да якты нуры бардыр.

Рейтинг күтәрү, кешеләрнең игътибарын җәлеп итү өчен аянычлы вакыйгалар иң отышлысы икәнен аңлыйм инде мин. Алар кызганычрак, аяусызрак, канлырак булган саен укучылар да күбрәк җыелачак. Ләкин...

Мин коткыга бирешмәскә тырышам инде. Үземне төрлечә дәртләндерергә маташам. Ләкин юк-юк дигәндә дә, теге уй калкып чыга. Бик карт та түгелмен бит әле. Эшләр дә хәтсез җыелган. Әгәр өлгерәлмәсәм?

Икенче көнне махсус сораштырдым. Ковидтан үлүче булмаган, бик авыр хәлдәге дүрт кеше үзен яхшырак тоя башлаган, тугыз кеше савыгып чыккан. Мин шатландым. Яшәргә теләсәң, өмет табыла икән. Эзләгән өткә сәяк бетмәгән.

Дәвамы киләсе саннарда >

Белми калмагыз!

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

1 2022 елның беренче яртыеллыгына 6 айга «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 Язылу квитанциясен безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

Җиңүче жирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, жирәбә 20 гыйнвар көнне үткәреләчәк.

Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

- ✓ мини-тракторлар;
- ✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
- ✓ жир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ



1 **ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ**

2 **ОНЛАЙН:** vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR-код ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

Сөенечле хәбәр!

2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре

П2435 ~~465 сум~~ **404,04 сум** атнага бер, җомга килә

П2409 ~~1000,92 сум~~ **859,08 сум** Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә

6–16 декабрь көннәрендә ташламалы бәяләр!

Реклама 16+

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ (843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru

- Ерткыч кош
- Бөтеннең аерым кисәге
- Саран
- Якын, әмма тешләп булмый
- Куркыныч, дәһшәт
- ...-йомалак
- Тар
- Татар телендәге килеш
- Совет космонавты
- Думави, Мадьяров
- Төрле төстәге
- Пәйгамбәр
- Европаның көнбатышындагы борын
- ... Дакаскос
- Кучемсез милектән вакытлыча файдалану
- ... Батулла
- Чүпрә, камыр башы
- Теш пастасы савыты
- Чиктән артык китү
- Үги ... яфрагы
- Виноград сорты
- Яңадан, тагын
- Вест-Индиядәге утрау-дәүләт
- Гомер поэмасы
- Фатих Хөсни хикәясе
- Сербия каласы
- Россия кинопремиясе
- Ык кушылдыгы
- Геометрик җисем
- Зодиак билгесе
- Пеләшкә үсми
- Сунарчы

Рәис Габдулла

3 декабрь санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: шатлану, Ио, Римский, Асо, скиф, рад, Ив, сыер, Ломе, Ай, Зураб, Сомали, Оша, Сиваш, колли, мим, Исәнбәт, Зилә, муар. **Вертикаль буенча:** сак, Киото, сом, Мүлмә, Шәрәфиева, линза, имбир, тимер, ЗИС, әл, Лос, асау, үтәү, Кадыйрова, Наис, аша, йомрыбаш.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 1978 елда Казан Бөтенсоюз социалистик ярышында югары казанышларга ирешкәне өчен нәрсә белән бүләкләнә?
А) алтын папирус;
Б) бәллүр ябалак;
В) кучмә Кызыл байрак.

2 Автономия ул – ...
А) автомобильгә номер ала торган урын;
Б) милли яки социаль төркемнең хокукый хәле;
В) мобиль техник система.

3 «Казанда тору күңелле, Уральски бик сирәк искә төшә. «Шүрәле» китабы җибәрдем. Монда кечкенә вакытымда тәрбия иткән әнкәмне дә таптым». Тукайның бу хаты кемгә атап язылган?
А) Газизә Госманова;
Б) Галимҗан Баруди;
В) Заһидә Тинчурина.

4 1995 елда республика үзенең беренче юбилеен билгеләп үтә. Бәйрәмгә ул вакытта Россия Федерациясе Премьер-министры булган ... килә.
А) Путин;
Б) Кириенко;
В) Черномырдин.

Җаваплар: 1) В; 2) Б; 3) А; 4) В.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 17167 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 380

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+